

КАЙГЫРТУДАН БАШЛАНА
Сәламәтлек саклау тармагында нинди яңалыклар бар?

> 3

ЗАТЛЫ СҮЗ
Арчада каләмдәшебез Риман Гыйлемхановның юбилей кичәсе узды

> 4

ЧӘРШӘМБЕМЕ, ҖОМГАМЫ?
Камал театрында – премьера

> 5

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА
Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

>8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 19 (29179) | Сишәмбе | 13 февраль | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

Нәтиҗә

РОБОТЛАР НИК КӨРӘМИ?

4,7 триллион сумлык товар, кадрлар кытлыгы һәм тармакны автоматлаштыру. Башкалада республиканың Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының еллык коллегия утырышы узды. Анда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Авырткан җирдән кул китми дигәндәй, эшче көчләр җитмәү мәсьәләсен утырышта кат-кат күтәрделәр. Студентларга да, роботларга да өмет итәләр.

tatarstan.ru

Татарстанның сәнәгать тармагында былтыр 4,7 триллион сумлык товар төяп озатканнар. Әлеге хезмәтнең зур өлеше нефтьчеләргә туры килә, әлбәттә. Машина төзүчеләр дә кара алтын чыгаручылардан калышмый. Беренче өчлеккә нефтьне эшкәртү өлкәсе дә эләккән.

– Нефть чыгару күрсәткечен узган ел дәрәҗәсендә саклап кала алдык. Барлык кыенлыкларга да карамастан, нефтьне эшкәртү 1 миллион тоннадан да күбрәккә артты. Моның нәтиҗәсе буларак, республикада бензин җитештерү 11 процентка үсте, – дип сөйләде тармакта ирешкән уңышлар турында вице-премьер, сәнәгать һәм сәүдә министры Олег Коробченко.

Сәнәгать тармагы өчен кадрлар мәсьәләсе көн кадагында тора. «Бүген республикада 11 меңнән артык эшче, инженер, технолог җитми. Ә алдагы җиде елда безгә 166 мең кеше әзерләргә кирәк. Эшкә сәләтле халык саны кими. Шул ук вакытта аларның яртысыннан да күбрәге җитештерүгә бәйле булмаган тармакларда хезмәт итә», – диде министр.

Мәсьәләне чишү юлы буларак, эшчеләрне яшәү урыны белән тәэмин итәргә кирәк, диделәр утырышта. Зур оешмалар шулай эшли башлаган да инде. Былтыр, мәсәлән, «Хайер» 900 урынга исәпләнгән тулай торак төзегән. «Алабуга» махсус икътисадый зонасында инфраструктурасы булган торак комплексын кулланышка тапшырганнар. «Бер эшчегә торак төзү уртача 1,5 миллион сумга төшә», – диде министр. Фикерен дәвам иттереп: «КАМАЗ һәм Чаллы тулай торaклар белән төзелде», – дип өстәде.

Кадрлар әзерләү мәсьәләсенең әһәмиятен Рөстәм Миңнеханов та искәртте. Аның фикеренчә, мигрантлар белән эшне көчәйтергә кирәк, алардан башка бу мәсьәләне хәл итеп булмаячак.

– Бу юнәлештә федераль дәрәҗәдә дә тәкъдимнәребез бар, аларны ил Хөкүмәтенә юлладык, – диде Татарстан Рәисе.

Ничек кенә булмасын, үзебездәге мөмкинлекләрдән яхшырак файдаланырга кирәк, диде Рөстәм Миңнеханов. Бүген республикада сәнәгать тармагына кадрлар әзерләү белән 38 көллият шөгыльләнә. Аларда белем алучыларның 23 проценты гына тулай торакта урын белән тәэмин ителгән. Шуңа күрәме, бүген республикадагы һөнәри уку йортларында илнең башка төбәкләреннән килгән студентлар саны 10 процентка да тулмый.

Утырышта тагын бер нәрсәгә игътибар юнәлттеләр: шул ук машина төзү тармагы өчен белгечләр әзерләү күрсәткече хезмәт базарында таләп ителгәннән биш тапкыр кимрәк. Ә хезмәт күрсәтү өлкәсендә – киресенчә. Шуңа күрә һөнәри уку йортларында белем бирү юнәлешләрен яңадан карап чыгарга җыеналар.

Уку тәртибе дә үзгәрмәгәе. «Алабуга» махсус икътисадый зонасы генераль директоры Тимур Шаһивәлиев республикада вуз, техникум һәм көллиятләрдә укуны кичке якка күчерүгә бәйле тәҗрибә рәвешендәге проект башларга тәкъдим итте.

– Кадрлар кытлыгы мәсьәләсен хәл итү өчен, югары һәм урта һөнәри белем бирү йортларының көндезге бүлекләре студентларына 17.00 сәгатьтән соң уку мөмкинлеген булдырырга кирәк. Шул рәвешле, икътисад тармагына 235 мең кадр җәлеп итеп булачак, – диде генераль директор.

Аның әйтүенчә, яңа проект хезмәт базарын ел саен 10 меңнән артык эшчегә баетачак. Ә 2030 елга эшче студентлар саны 298 мең кешегә җитәчәк. «Элек кая да булса барып урнашу өчен, башта укырга кирәк иде, хәзер эш үзе көтә», – диде Тимур Шаһивәлиев.

Кадрлар кытлыгы мәсьәләсе зур оешма-предприятиеләрне генә түгел, район җирлекләрен дә борчый. Бу уңайдан Менделеевск районында тикшерү дә үткәргәннәр.

– 2021 елда районда 15–18 яшьлек 281 чыгарылыш сыйныф укучысы районнан читкә киткән. Бу – мәктәпне тәмамлаучыларның 90 проценты дигән сүз, – дип сөйләде район башлыгы Радмир Беляев. – Районда яшәүче 14–35 яшьлекләр арасында үткәрелгән сораштырудан күренгәнчә, егет-кызларның өчтән икесеннән дә күбрәге читкә чыгып китүне гадәти күренеш дип саный.

> Еллык коллегия утырышында Татарстан һәм Мари Эл Хөкүмәтләре арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, мәдәни һәм башка өлкәләрдә хезмәттәшлек турында килешү имзаланды. Документка Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Мари Эл башлыгы Юрий Зайцев кул куйды.

Утырышта катнашкан Россия сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Альберт Кәримов сәнәгатьне роботлаштыруга да игътибарны арттырырга киңәш итте.

Бу хакта сөйләгәндә Олег Коробченко: «Киләчәк турында хыялланганда, роботлар кар көрәр, ә без иҗат итәрбез дип уйлаган идек. Тик бүген иҗат белән нейрочелтәр шөгыльләнә, без исә кар көрибез», – дип әйтеп куярга да мәҗбүр булды.

Рөстәм Миңнеханов та роботларның мода гына түгеллеген искәртте. Гомумән алганда, Татарстан Рәисе тармак эшен уңай бәяләде.

– Дәүләт башлыгы тарафыннан билгеләнгән төп бурыч – илебезнең иминлеген, технологик суверенитетны тәэмин итү, – диде Татарстан Рәисе. – Бу юнәлештә бик зур эш башкарылды. Дәүләт ярдәменнән башка икътисадта да, сәнәгать тармагында да мондый зур уңышларга ирешеп булмас иде. Шуңа күрә Россия Президенты Владимир Путинга, ил Хөкүмәтенә зур рәхмәт.

Форсаттан файдаланып, Рөстәм Миңнеханов махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә даими ярдәм кулы сузып торучы оешма-предприятие вәкилләренә дә ихлас теләкләрен җиткерде.

Карлы Казан

Казан Россиянең иң карлы шәһәрләре рейтингында икенче урынга чыккан. «Gismeteo» мәгълүматларына караганда, башкалабызда кар катламы биеклеге 92 сантиметрга җиткән. Бу күрсәткеч бары тик Саранск шәһәрендә генә бездәгедән югарырак – 96 см, Ульяновск һәм Түбән Новгород шәһәрләре (икесендә дә – 75 см) өченче урынны алган. Самарада 71 сантиметр калынлыкта кар катламы барлыкка килгән. Шулай ук Иваново (71 см), Ижевск (69), Чиләбе (67) һәм Владимир (66 см) шәһәрләре дә кар иң күп яуган шәһәрләр исемлегенә кергән.

Без – бишлектә

Узган елгы нәтиҗәләр буенча, Татарстан тормыш сыйфаты ягыннан Россиянең иң шәп 5 төбәге исемлегендә калган. Республика алдагы елда дүртенче урында булса, хәзер Краснодар краен (4 нче урында) алга уздырып, бишенче урында урнашкан.

РИА Новости төзегән рейтингка ышансаң, гомумән, күпчелек төбәкләрдә тормыш сыйфаты яхшырган. Бары тик Чукотка автономияле округында, Белгород, Магадан һәм Псков өлкәләрендә генә бу җәһәттән берникадәр артка китеш теркәлгән. Ә инде беренче өч урынга, алдагы елдагы кебек үк, Мәскәү, Санкт-Петербург калалары һәм Мәскәү өлкәсе чыккан.

Күреп торалар

Узган елда ЮХИДИ юлда йөрү кагыйдәләрен бозучыларга карата ил күләмендә барлыгы 237,6 миллион штраф салган. Алдагы елдагыга караганда 18,1 процентка зуррак сан бу. Россия Эчке эшләр министрлыгы матбугат хезмәте мәгълүматларына караганда, штрафларның 92 проценты юл камералары ярдәмендә салынган.

Хәзерге вакытта илебез юлларында камералар саны 8,4 процентка артып, 29,2 меңгә җиткән.

Мәскәү (41,4 миллион штраф) һәм Мәскәү өлкәсе (39,9 миллион) йөртүчеләрне иң еш штрафка тартучылар булып чыккан. Шулай ук Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсе (13,9 миллион), Татарстан (8,31 миллион), Башкортстан (6,79 миллион), Краснодар крае (5,73 миллион), Самара өлкәсе (5,26 миллион) дә бу җәһәттән лидерлар исәбенә кергән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Коммуналь хуҗалык

«Газ»лы кушымта

ЗӘҢГӘР ЯГУЛЫК ӨЧЕН ТҮЛӘҮ ҖИҢЕЛӘЯ

Тиздән Татарстанда яшәүчеләр газ белән тәэмин итү һәм җиһазларга техник хезмәт күрсәтү килешүләрен өйдән чыкмыйча гына, электрон имза ярдәмендә төзи алачак. Ул арада газ өчен түләү һәм исәпләгеч күрсәткечләрен тапшыру эше җиңеләйгән.

Газ кулланучыларның тагын бер мәшәкате кимегән. Узган ел азагында Татарстанда зәңгәр ягулык кулланучылар – абунәчеләр белән исәп-хисап ясау һәм үзара элемтә платформасы (ПРиВА) гамәлгә кергән. Озын сүзнең кыскасы, хәзер газга бәйле түләүләрне кесә телефонындагы махсус кушымта аша да башкарып була.

– Мобиль кушымтада гади кулланучы өчен кирәкле бөтен мәгълүмат та бар. Газ өчен түләү һәм исәпләгеч күрсәткечләрен тапшырудан тыш, биредә моңа кадәр түләнгән квитанцияләр дә саклана. Шулай ук, исәпләгечнең куллану вакыты кайчан чыгасын да белеп була, – дип сөйләде «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган чарада «Газпром трансгаз Казан» оешмасы генераль директорының икътисад һәм финанслар буенча урынбасары Руслан Фәтхелисламов.

Аның әйтүенчә, республика илнең биш төбәге белән беррәттән тәҗрибә рәвешендәге эштә катнаша. «Яңа платформа үзенең нәтиҗәлелеген раслады инде», – дип тә өстәде Руслан Фәтхелисламов. Татарстанда 1,6 миллион газ кулланучы исәпләнә. Шул исәптән 315 меңнән артык абунәче кесә телефонына яңа кушымтаны урнаштырган да инде.

Ай-һай, газ бүлекчәләре хезмәткәрләренең бу арада эшләре болай да күптер. Форсаттан файдаланып, Руслан Фәтхелисламовтан узган ел азагында газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү килешүләрен яңадан төзүгә бәйле рәвештә килеп чыккан шау-шу турында да сорадылар. Хәтерләсәгез, халык арасында 2024 елның 1 гыйнварына кадәр әлеге документны яңадан имзаламасаң, зәңгәр ягулыкны өзәчәкләр, дигән хәбәр таралганнан соң, абунәчеләр газ бүлекчәләренә озын-озак чиратка тезелде. Килешүләрне яңарту эше быел да дәвам итә. «Аны мобиль кушымта аша гына имзалап булмыймы?» – дип кызыксындылар газ оешмасы вәкиленнән. Әлегә мондый мөмкинлек юк. Әмма тиздән Татарстанда яшәүчеләр газ белән тәэмин итү һәм җиһазларга техник хезмәт күрсәтү килешүләрен өйдән чыкмыйча гына, электрон имза ярдәмендә төзи алачак, дип вәгъдә итте Руслан Фәтхелисламов. Бүген бу юнәлештә дә эш бара икән.

Сүзгә-сүз



Антон НЕМКИН, Россия Дәүләт Думасының Мәгълүмати сәясәт, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә комитеты әгъзасы:

Яшьләрне интернетта үз-үзләрен тотарга өйрәтү – дәүләт, бизнес һәм һәр укучының әти-әнисе бергәләп башкарырга тиешле өстенлекле бурычларның берсе. Тиз ышанучанлыклары аркасында алар кырыгалдарлар корбанына әйләнә.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – ЮГАРЫ БЕЛЕМ

25% >> югары белем
40% >> урта һөнәри белем
19% >> урта гомуми (10–11 нче сыйныф)
10% >> төп (9 нчы сыйныф)

Югары белемлеләр
28% >> хатын-кызлар / **23%** >> ир-атлар

**Халык санын исәпкә алу нәтиҗәләре буенча*

Өйдән-өйгә

17 февральдә Татарстанда яшәүчеләргә Россия Президентын сайлау турында өйдән-өйгә йөреп сөйли башлаячаклар. Бу эш белән участок сайлау комиссияләре әгъзалары шөгыльләнәчәк. «Информ УИК» проектында 10 меңгә якын кеше катнашачак.

Алар Россия Президентын сайлау символикасы сурәтләнгән ак япма киеп, күкрәгенә Россия флагы төсләрендәге V хәрефе рәвешендә махсус значок тагачак. Мәгълүмат кампаниясен үткәрүгә вәкаләтле бу кешеләр шулай ук мәгълүмати буклетлар, бейдж һәм таныклыкка ия булырга, үзләре белән паспорт йөртергә тиеш.

Өйдән-өйгә йөрүчеләр сайлауга кагылышлы төрле сорауларга җавап бирә алачак. Мәсәлән, сайлау участогының кайда урнашуын, өйдә тавыш бирү өчен ничек итеп гариза тапшырырга яки «Мобиль сайлаучы» системасыннан ничек файдаланырга икәнен аңлатачак. Үзләре исә сайлаучыларның тавыш бирергә җыену-җыенмауларын, ни рәвешле тавыш бирәчәкләрен, комиссия телефоны номерын белү-белмәүләрен ачыклаячак. Татарстан Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Андрей Кондратьев аңлатып үткәнчә, мондый кешеләргә шәхси документларны күрсәтү таләп ителми. Аларны өйгә кертергә, шәхси документ күрсәтергә яки мәгълүмат җиткерергә дә кирәкми.

Россия Президентын сайлау өч көн – 15, 16 һәм 17 мартта уздырылачак. Сайлауга 4 кандидат: бүгенге дәүләт башлыгы Владимир Путин (үзен үзе тәкъдим иткән), Владислав Даванков («Новые люди» партиясеннән), Леонид Слуцкий (ЛДПР) һәм Николай Харитонов (КПРФ) кертелгән.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ПАКЬСТАН: САЙЛАУ ТӨГӘЛЛӘНДЕ, КӨРӘШ ДӘВАМ ИТӘ

Үткән атна уртасында Пакьстанда парламент сайлавы үтте. Илдә сәяси хәл киеренке: террор актлары бик еш кабатлана, элекке Премьер-министр Имран Хан коррупциядә, дәүләт серен ачуда гаепләнеп, 31 елга төрмәгә утыртылды.

Икътисадый хәл дә начар. Хакимиятләр Имран Хан партиясенә сайлауда катнашырга рөхсәт бирмәде, чөнки аңлашыла иде: тоткынлыктагы элекке хөкүмәт җитәкчесе үзе дә, аның партиясе дә халыкта популяр, сайлауда катнаштырсаң, җиңәчәкләренә шик юк. PTI – «Гаделлек өчен көрәш» (тыелган партиянең исеме шундый) вәкилләре бәйсез кандидатлар буларак сайлауда катнаштылар һәм җиңделәр дә. Сайлау төгәлләнеп, берничә сәгать үтүгә, «Ватаным Татарстан» хәбәрчесе кулына әлегә рәсми рәвештә игълан ителмәгән беренче мәгълүматлар килеп керде. PTI парламентта 154 урын алырга тиеш дип санала, аның белән көндәш партияләр кырык җидешәр урын яулаганнар. Әмма сайлау комиссиясе авызына су капты: ике көн берни дә эндәшмәде. Ике көннән соң гына чит ил агентлыклары рәсми дип саналган саннарны игълан итте. Reuters мәгълүматлары буенча Имран Хан партиясе 101 урын яулаган. Рәсми саннар да эзәрлекләнгән партия вәкилләренең күпчелек урынга ия булганын раслый, әмма ил законнары буенча алар хөкүмәт төзи алмыйлар.

Икенче урындагы «Мөселман лигасы» дип аталган партия күпчелеккә ирешмәсә дә, башка партияләр белән коалициягә кереп, хөкүмәт төзү хокукы ала. Ул партия лидеры Нәвәз Шәриф тә берничә тапкыр Премьер-министр булып торган һәм төрмәдә дә утырып чыккан. Пакьстанда Премьер кәнәфиеннән төрмә камерасына юл якын. Имран Хан үзен яклаучыларны протестка чыгарга өндәде. Ял көннәрендә каршылык акцияләре булды. Ярсыган халык: «Чор! Чор!» – дип кычкырып (безнеңчә «карак» дигән сүз) урамнарда йөрде, әмма атом державасы булган илдә хәрбиләр дилбегәне нык тота.

Ял көнне Финляндиядә дә Президент сайлауның икенче туры үтте. Анда, 51,6 процент тавыш җыеп, Александр Стубб җиңде. Ул Россиягә каршы карашлары белән мәгълүм. Күп еллар буе СССР, аннан соң Россия белән яхшы мөнәсәбәтләр саклаган Финляндия, махсус хәрби операция башланганнан соң, дошманга әйләнде.

Америкада да сайлау алды көрәше кыза. Байден сайлаучылар белән очрашу вакытында бар кешене шаккатырырлык сүзләр сөйләп йөри. 1996 елда үлгән Франция Президенты Миттеран белән берничә көн элек кенә очрашуын әйтә, шулай ук каберлеккә күчкән Германия канцлеры Коль белән дә очрашып тора икән. Ниһаять, рәсми хакимиятләр дә аның авыру икәнен таный башлады һәм бу кешенең сайлау марафоныннан төшеп калу ихтималы артты.

Россиядә

ИЛГӘ КЕШЕ КИРӘК

Россия Фәннәр академиясе икътисадчылары илнең яңа үсеш моделе турында баш вата. Чимал сатып баюга корылган үсеш моделе үзенең мөмкинлекләрен кулланып бетерде дип саный алар. Моннан соң технологик модернизация юлын эзләргә туры киләчәк.

Торак төзелешенә гигант акча белән ясалган инвестицияләр технологик үсешкә хезмәт итми. Белгечләр монысын да таный. Әмма тораксыз да булмый. Илгә кешеләр кирәк, яшәү мәйданыннан башка гына туу күрсәткечләрен яхшырту мөмкин түгел. Кеше саны эшче куллар буларак кына түгел, базар буларак та кирәк. Җитештерелгән продукцияне кемнәрдер сатып алырга тиеш. Россиянең технологик продукциясе белән тышкы базарларга чыгу кыен: бердән, санкцияләр чолганышында яшибез, икенчедән, һәр ил үз продукциясен урнаштыруны кайгырта. Россиягә чимал кушылдыгы буларак кына карап өйрәнделәр.

Беренче карашка Россия икътисады импортны алыштыру хисабына үсәргә тиеш төсле. Импортны алыштыру дигәндә, без нигездә сыйфаты һәм бәясе белән чит ил товарларына көндәш була алырлык продукцияне күз алдында тотабыз. Дөнья илләре тәҗрибәсе шуны күрсәтә: импортны алыштыру тышкы базарларга чыкмый гына мөмкин түгел. Бик яхшы сыйфатлы технологик продукт ясасаң да, бәясе көндәшлеккә сәләтле булсын өчен, аны күпләп җитештерү таләп ителә. Бер эчке базар гына массакүләм җитештерүне тәэмин итә алмый. Демографик кризис шартларында эчке базар да кысыла бит әле аның.

Халык санын арттыруның бер юлы бар һәм ул кулланыла да иде. Ватандашларны илгә кайтару программасы күптән эшләп килә. СССР таркалганнан соң чит илләрдә яшәп калган рус, татар һәм башка Россия халыкларын туган илгә җәлеп итү турында бара сүз. Мигрантлар китерүгә караганда отышлырак юл бу. Әмма 2023 ел нәтиҗәләре ватандашларның да тарихи нигезгә атлыгып тормауларын күрсәтә. Эчке эшләр министрлыгы статистикасы үткән ел 63,6 мең кешенең кайтырга теләк белдерүен, 45,1 меңенең генә кайтып урнашуын күрсәтә. Чагыштырыйк: 2021 елда гариза бирүчеләр – 113,1 мең, кайтучылар 78,5 мең булган. Кимүнең сәбәбе: махсус хәрби операция һәм программаның үз кимчелекләре, диләр Дәүләт Думасында. Илгә кайтырга теләгән яшь ватандашлар саны аеруча нык кимегән.

РӘСМИ ТАТАРСТАН

ХЫЯЛГА БЕР АДЫМ

КАЗАН «КИЛӘЧӘК УЕННАРЫ» ТУРНИРЫН КАБУЛ ИТӘРГӘ ӘЗЕР

tatarstan.ru

Чиксез горурлык та, олы җаваплылык та. Татарстан башкаласы барлы-юклы бер атнадан соң дөнья тарихында тәүге тапкыр узачак «Киләчәк уеннары» турнирын кабул итәчәк. Оештыручылар Казанның әзерлегенә «бишле» куеп китте инде.

Уеннарга башкала 450 көн әзерләнде. Әзерлек барышы федераль җитәкчелекнең дә күз уңыннан чыкмады. Узган атна азагында Россия вице-премьеры Дмитрий Чернышенко, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Киләчәк уеннары»н оештыру эшләре белән кабат танышты.

Вице-премьер аккредитация бирү системасын тикшерде (сүз уңаеннан, үзләре дә уеннарга аккредитация узды), волонтерлар белән аралашты, «Казан Экспо»да уеннарның барлык объектларындагы мәгълүматны туплый торган махсус үзәктә булды. Ул-бу була калса, әнә шул үзәк җаваплы.

– Турнир башланырга бик аз вакыт калды. Президент Владимир Путин кушуы буенча 1,5 ел эчендә нульдән барлыкка килгән турнирга бәйле бик күп эш башкарылган, – диде вице-премьер. – Хәзер инде тизлекне киметергә ярамый, безнең уртак бурычыбыз – «Киләчәк уеннары»н иң югары дәрәҗәдә үткәрү.

Дмитрий Чернышенко хәбәр иткәнчә, иң күп катнашучыларны Кытайдан көтәсе икән. Катнашучылар аеруча да фиджитал-футбол һәм фиджитал-баскетбол төрләрендә күп, ди.

Логистика – иң мөһиме. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов искәрткәнчә, 100дән артык илдән килүче 2 меңнән артык кунакны кабул итү – зур җаваплылык.

Дмитрий Чернышенко билгеләп үткәнчә, әлеге турнирга бөтен дөньяның игътибары юнәлгән. Шул исәптән дустанә булмаганнарның да. Моңарчы күрелмәгән мәгълүмати басымга да әзер торырга, хәвефле хәлләрне булдырмый калырга кирәклеген әйтте ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Владимир ПУТИН,
Россия Президенты:
– «Киләчәк уеннары» бер мәйданчыкта киберспорт һәм спортның классик төрләрен берләштерәчәк. Хәзерге заман кешесе, киләчәк кешесе ул – физик һәм интеллектуаль яктан үсеш алган кеше. Уеннар әнә шуны раслаячак та. «Киләчәк уеннары» бу хакыйкатьне тулысы белән ачарга мөмкинлек бирер дип ышанам.

САН

- «Киләчәк уеннары»нда катнашуы турында 107 ил белдергән. Барлыгы 277 команда килер дип көтелә. Искәртеп үтик: бу бер илдән җыелма команда дигән сүз түгел, биредә аерым төркемнәр ярыша. 2 меңнән артык катнашучы киләчәк.
- Уеннарда чит илдән дә волонтерлар булачак. Аларның саны – 121. Болар – Греция, Бөекбритания, Төркия, Латвия, Ливан, Италия һәм башка ил вәкилләре. Турнирда барлыгы 2 меңнән артык волонтер ярдәм итеп торачак.
- Уеннарны 3 млрд кеше карар дип фаразлана (онлайн мәйданчыклар, телетрансляцияләрне исәпкә алып).
- Турнир 21 февраль – 3 март көннәрендә узачак.

Парламент дәресләре

Югалмасын тавыш

Кичә Казанның 187 нче лицее сайлау участогына әйләнгән иде. Уйнап түгел, чынлап. Биредә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашында «парламент дәресе» үтте. 11 Б сыйныф укучылары үзләренең гражданлык бурычын, сайлауларга карата мөнәсәбәтен күрсәтте.

Быел «парламент дәресе» 5 февральдә башланды. Ул 17 февральгә кадәр дәвам итәчәк. Темасы: «Киләчәкне сайлыйбыз». Мондый исемне сайлау юкка түгел, 15–17 мартта – Россия Президентын, сентябрьдә Дәүләт Советына депутатлар сайлау узачак. 2025 елда исә Татарстан Рәисен сайлау көтелә.

«Түгәрәк өстәл» рәвешендә узган «парламент дәресе»ндә укучылар башта партияләргә бүленеп, үз программаларын тәкъдим итте. Әйтик, «Зур тәнәфес» партиясе вәкилләре балаларның карандаш, каләм, бетергечләрен еш югалтуын исәпкә алып, мәктәптә уку кирәк-ярагын сата торган махсус банкомат булдырырга вәгъдә итә. «Яшь профессионаллар» партиясе, мәктәптә ял итү почмагы кирәк, ди. Ә «Беренчеләр советы» җирле үзидарә көнен елга бер генә түгел, айга дүрт мәртәбә уздырырга кирәклеген әйтте. Әлеге программаларның кайсы җиңәчәк? Шуларга тавыш бирү оештырылды.

Сайлаучылар бюллетеньнәрне махсус әрҗәгә салды. «Исәп палатасы» белгечләре дә чакырылган иде. Сайлауның гадел үтү-үтмәвен күзәтүчеләр карап торды. Кыскасы, укучылар сайлауның бар этаплары белән танышты. Ә җиңгән проектны лицейда тормышка ашырырга туры киләчәк. Нәтиҗәдә иң күп тавышны «Зур тәнәфес» программасы җыйды. Алар исәбендә – 12 тавыш.

– Карандаш, каләм, блокнотлар банкоматы булдырачакбыз. Сез ризамы? Хәзер инде: «Каләм язмый, паста беткән», – дип сәбәп таба алмыйсыз, – диде лицей директоры Гөлнара Галиева.

Фәрит Мөхәммәтшин заманча мәктәптәге мөмкинлекләргә, шулай ук укучыларның әзерлегенә соклануын яшермәде.

– Монда килүемнең сәбәбе – әлеге уку йорты эшчәнлеге, дәресләрнең ничек узуы, яшьләрнең сайлау хакында нәрсәләр белүе турында кызыксыну. Мондый дәресләрнең мәктәптә үтүе мөһим. Киләчәк яшьләрдән тора, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Яңа лицейда белем алырга, иҗтимагый, яшьләр оешмалары оештырып, тормыш рәвешен күрсәтергә барлык мөмкинлекләр дә бар. Алар шушы тормыш белән яшиләр дә.

Дәүләт Советы Рәисе әйтүенчә, әлеге дәресләр укытучыларга да, укучыларга да җаваплылыкны арттырып, сайлауда катнашучылар күбрәк булсын, дигән ният белән оештырыла. Балалар кандидатларны да яхшы белә. Аларга сайлауда катнашучыларның бурычын аңлаттык. «Уйлавымча, сайлауга халыкның 80–90 проценты килер, алар битараф калмаслар», – диде Фәрит Мөхәммәтшин, дәрестән соң журналистларга.

Сәрия МИФТАХОВА

АТКА ПЕЧӘН КЕМ САЛА?

Борчыган мәсьәлә

Бүген Татарстанның авыл хуҗалыгы тармагында 69 мең кеше эшли. Шул ук вакытта ел башындагы мәгълүматларга караганда, агросәнәгать комплексында 2600 эш урыны бар. Авыл хуҗалыгы тармагына нинди белгечләр җитми? Без шул хакта белештек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Әлмәт районының Бишмунча авылында яшәүче Айдар Габдрахманов, укуын тәмамлагач, авылга зур өметләр баглап кайта. Тик ветеринар булып эшләп алган хезмәт хакы зур гаиләсен туйдырырга җитми башлый. Өч балалы гаиләгә зур куыш та кирәк бит.

– Ветеринария хезмәтендә 4 ел эшләдем. Эшемне яратып һәм чын күңелдән башкардым. Баштагы вакытларда бар да яхшы, әйбәт иде. Рәхәтләнеп эшләргә шартлары да җитәрлек. Тик яшьләргә ярдәм булмау авырлыклар тудырды. Шәхсән мине хезмәт хакының аз булуы һәм торак мәсьәләсе борчыды. Йорт булмасмы икән, дип йөрдем-йөрдем дә, тәвәккәлләп, нигезен салып куйдым. Менә хәзер шуны сафка бастырырга кирәк, шуңа күрә яраткан эшемне калдырып, башка өлкәгә күчәргә туры килде. Авыл хуҗалыгында эшләүче яшь белгечләргә килешү нигезендә йортлар салу мөмкинлеге булса, рәхәтләнеп эшләр идем югыйсә. Лаеклы хезмәт хакын түләп, аның бер өлешен фатир яки йорт өчен алып барсалар да, каршы булмас идек, – ди Айдар.

«Татарстан Республикасы Аграр яшьләр берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Диләрә Шувалова сүзләренчә, тармакта аеруча тракторчылар, сыер савучылар, азык-төлек һәм эшкәртү предприятиеләре белгечләре, мал табиблары һәм агрономнар җитми. Аның фикеренчә, моңа түбән хезмәт хакы, яшь белгечләрнең авылда яшәргә теләмәве, авыр физик хезмәт сәбәпче. Шулай ук югары квалификацияле белгечләргә дә кытлык зур.

Статистика мәгълүматлары буенча, авыл хуҗалыгы тармагында эшләүчеләрнең 24 проценты – югары, 37 проценты – урта махсуслашкан белемле кешеләр. Соңгы өч елда механизатор, сыер савучыларның күп өлеше пенсиягә чыгар яшькә җиткән. Ә менә яшьләр нибары 10 процентны гына тәшкил итә. Авыл хуҗалыгы ел саен яшь кадрлар белән тулыланып торырга, оешмаларга килеп, өлкән буынның тәҗрибәсен алырга тиеш тә бит. Алга таба да болай барса, авыл хуҗалыгында кем эшләр?

Чистай районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы урынбасары Илгизәр Нуретдинов әйтүенчә, районда механизаторлар һәм сыер савучылар җитәрлек. Ә менә агроном һәм инженерларга кытлык.

– Яшьләрне авылга кайтару бик авыр хәзер. Яхшы хезмәт хакларын эре агрохолдинглар гына тәкъдим итә ала, гади хуҗалыкларда зур акча юк. Министрлыкның ярдәм чараларына хуҗалыкларныкы да кушылса, тагын да яхшырак булыр иде, – ди ул.

Диләрә Шувалова әйтүенчә, узган ел Ветеринария академиясен һәм Казан дәүләт аграр университетын тәмамлаучыларның күпчелеге үз һөнәре буенча эшкә урнашкан. Авылга кайтучылар шәхси клиникаларда һәм хезмәт күрсәтүче оешмаларда эшли башлаучыларга караганда күбрәк тә әле. Һәрхәлдә, саннар шуны сөйли. Ә менә колледж һәм техникум тәмамлаучылар арасында соңгы өч елда алган профессияләре буенча эшкә урнашучылар саны кимегән. Мондый статистикага, билгеле, һәр дүртенче егетнең армия сафларын тулыландыруы да йогынты ясый. Тәмамлаучыларның 10–11 проценты исә укуын югары уку йортында дәвам итә.

Билгеле булганча, авыл хуҗалыгы предприятиеләре студентларны максатчан да укыта. Килешү нигезендә югары уку йортында укыган очракта, чыгымнарның – 90, уртача белем бирү учреждениеләрендә белем алган очракта, чыгымнарның 30 проценты кире кайтарыла. Узган ел әлеге программада 78 предприятие катнашкан. Алар 406 студентны 14,2 млн сумга укыткан. Быелдан әлеге ярдәм 24 млн сумга кадәр арттырылган. Үз егет һәм кызларын Казан аграр университетында укытып чыгару өчен Балтач, Арча һәм Мөслим районнары аеруча тырышкан. Казан ветеринария академиясендә исә максатчан укучы Балтач, Биектау һәм Питрәч районнары студентлары күбрәк.

Эшкә урнашкан яшь белгечләргә бер тапкыр 300 мең һәм 150 мең сум акча бирелә. Моннан тыш, аларга ел дәвамында айлык хезмәт хакына 7,5 мең сум акча өстәмә каралган. Соңгы өч елда яшь белгечләрне үзләрендә калдыру өчен Арча, Кукмара, Саба, Балтач, Актаныш һәм Әтнә районнары аеруча нык тырыша. Ә менә Әгерҗе, Азнакай, Ютазы, Нурлат һәм Спас районнары бу программа буенча бик сүлпән эшли.

– Бу төр программада катнашырга теләүчеләрнең аз булуы аңа үзгәрешләр кертергә кирәклеге турында сөйли, – диде Диләрә Шувалова. – Без яшьләр арасында сораштыру уздырдык. Һәм алардан аңлашылганча, яшь белгечләрне түләүләрнең суммасы һәм аларны бирү шартлары канәгатьләндерми. Шуңа күрә без Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка бер тапкыр бирелә торган ярдәм чараларын 1 млн (югары уку йортын тәмамлаучылар өчен) һәм 750 мең сумга (урта махсуслашкан белем бирү йортларын тәмамлаучылар өчен) кадәр күтәрүне сорап мөрәҗәгать иттек. Шулай ук уку йортын тәмамлагач, эшкә урнашу вакытын өч елга кадәр озынайтуны һәм ярдәм чараларын арттыруны сорадык.

Зөһрә САДЫЙКОВА

2024 ГОД НАУЧНО-ТЕХНОЛОГИЧЕСКОГО РАЗВИТИЯ В ТАТАРСТАНЕ
ТАТАРСТАНДА ФӘННИ-ТЕХНОЛОГИК ҮСЕШ ЕЛЫ

АКЫЛ КӨЧЕ

КФУ галимнәре җәрәхәтне төзәтүнең яңа чарасын уйлап тапкан. Казан дәүләт архитектура-төзелеш академиясенең яңа табышы – туфракны ныгыту өчен универсаль модификатор. Татарстанда Фәнни-технологик үсеш елының ачылышында яшь белгечләр тәкъдим иткән кайбер ачышлар гына әле бу. Тантанада беренче тапкыр галимнәр гимны да яңгырады.

tatarstan.ru

Татарстан Фәннәр академиясендә узган чарада Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Россия фән һәм югары белем бирү министры Валерий Фальковны махсус күргәзмә белән каршы алдылар. Анда республика үсешенең төп юнәлешләре: медицина, авыл хуҗалыгы, нефть, мәгълүмат технологияләренә бәйле фәнни казанышлар урын алган. КФУдагы «Ген һәм күзәнәк технологияләре» лабораториясенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Яна Мөхәммәтшина нәселдән килүче сирәк очрый торган авыруларга каршы уйлап табылган дару тәкъдим итте. Университетның өлкән мөгаллиме Семен Романов исә Химия институты уйлап тапкан материал турында сөйләде. «Бүген сатуда яраны төзәтүче материаллар арасында канны туктату белән беррәттән, күпсанлы микробларны да бетерә торган эшләнмәләр юк. Безнең фәнни төркем шундый заманча каплавыч булдырды», – диде ул. Казан дәүләт архитектура-төзелеш академиясе мөгаллиме Николай Коноваловның табышы, ягъни туфракны ныгыта торган универсаль модификатор юл чыгымнарын киметергә, шул ук вакытта сыйфатны яхшыртырга ярдәм итәчәк. Хәзерге вакытта ул сынау үтә.

Яшьләргә мондый ачышлар ясарга республикада, илдә булган грантлар системасы ярдәмгә килә. Бу урында Валерий Фальков та республиканың грантлардан нәтиҗәле файдалануын әйтте. «Республика вузлары барлык федераль программаларда да катнаша. Университетларда фәнни-мәгариф үзәкләре, алдынгы инженер мәктәпләре булдырыла, студентлар арасында технологик эшмәкәрлек үсеш алды. Болар барысы да талантлы яшьләрне фәнгә тарту өчен кирәк», – диде федераль министр. Яшьләр димәктән, узган ел Татарстаннан ике фәнни коллектив фән һәм техника өлкәсендә Россия Хөкүмәте премиясе лауреатлары булды. Рөстәм Миңнеханов мондый уңышны башкалардан да өмет иткәнен әйтте.

Татарстан Рәисе әйтүенчә, Фәнни-технологик үсеш елын игълан итүнең мәгънәсе мондый: ул республиканың фәнне өстенлекле юнәлеш итеп күрүен аңлата. Әфәннәр академиясе республикада фәнни-техник сәясәтне гамәлгә ашыру өчен җаваплы үзәк вазыйфасын башкара. Академия гуманитар өлкәне үстерү, республиканың күпмилләтле халкының үзенчәлекле һәм бай мәдәни-тарихи байлыгын саклау өчен дә җаваплы.

Татарстан төбәкләрнең фәнни-технологик үсеше илкүләм рейтингында – икенче урында. Рөстәм Миңнеханов белдергәнчә, бездәге биш вуз «Приоритет 2030» программасында катнашып, иң яхшылар дип табылган. Шуларның икесе махсус грант откан. Икътисад өчен югары квалификацияле кадрлар әзерләүче, технологик мәсьәләләрне хәл итүче алты инженерлык мәктәбе эшли. Студентлар, фәнни хезмәткәрләр өчен шартларны яхшырту дәвам итә. Ике ел эчендә 2 меңнән артык урынга исәпләнгән ике тулай торак төзелгән.

– Татарстан халыкара мәгариф һәм фәнни-техник элемтәләрне үзгәртеп коруын дәвам иттерә. Дустанә илләр юнәлешендә, Көнбатыштан Көнчыгышка таба стратегик борылыш котылгысыз, – диде Рәис.

Россия Президенты Владимир Путин илнең технологик суверенитетына ирешү бурычын куйды. «Аны хәл итү өчен дәүләт хакимияте, җирле үзидарә органнары, югары уку йортлары, эшлекле бергәлек көчләрен бергә тупларга кирәк», – диде Рәис, сүзен йомгаклап. Ул индустриаль партнер компанияләргә фән-мәгариф комплексы оешмалары белән кооперацияне тирәнәйтү өчен күрелгән нәтиҗәле чаралар өчен рәхмәт әйтте. «Бизнестан, галимнәрдән һәм мөгаллимнәрдән яңа адымнар көтәбез», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Чарада Татарстан Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов яңа вице-президентларны тәкъдим итте. Алар – социаль-гуманитар юнәлеш буенча Айнур Тимерханов, табигый-фәнни юнәлеш буенча Ләйсән Әбҗәлилова, аналитика, халыкара һәм конгресс-күргәзмә эшчәнлеге, массакүләм мәгълүмат чаралары буенча Рөстәм Камалов, административ-хуҗалык тәэминаты буенча Дамир Гыйльметдинов. Марат Сафиуллин исә 1 марттан стратегия, икътисад һәм социология буенча вице-президент итеп билгеләнәчәк.

Сәрия МИФТАХОВА

Хәтер яңарту

Тарихи гаделлекне һәм дөреслекне кайтыру, Ватанга хөрмәт һәм мәхәббәт тәрбияләү, тарихи территорияләрне үстерү. «Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасының республикадагы бүлеге узган елга нәтиҗә ясады һәм быелга бурычлар билгеләде.

Җыелышта Татарстан Рәисе Администрациясе башлыгы Әсгать Сәфәров «Россия хәрби-тарихи җәмгыяте»нең республикадагы бүлеге рәисе итеп сайланды.

– Мондагы һәр кеше – үз иленең һәм республикасының патриоты, алар үз Ватанын, үз халкын ярата, үз тарихын хөрмәт итә һәм аны беркемгә дә үзгәртергә ирек бирми. Сезнең белән алга таба да тарихи гаделлекне торгызу белән шөгыльләнәчәкбез дип ышанам. Мөһим бурычларның берсе – һәр районда безнең бүлекне булдыру, яшьләребездә Ватанга хөрмәт һәм мәхәббәт тәрбияләү, – диде ул.

Очрашуда Россия хәрби-тарихи җәмгыятенең төбәк сәясәте Департаменты директоры Аяна Шойгу да катнашты.

– Әсгать Әхмәтович – хөрмәтле һәм нәтиҗәле җитәкче, аны сезнең игътибарга тәкъдим итү – минем өчен зур дәрәҗә. Сезнең белән бергә зур проектлар тормышка ашырырбыз дип ышанам, – диде ул.

Аяна Шойгу «Россия хәрби-тарихи җәмгыяте»нең узган елгы эшчәнлегенә нәтиҗә ясады һәм быелгысының өстенлекле юнәлешләрен билгеләде.

– Төп юнәлеш – төбәкләрне, шул исәптән тарихи территорияләрне үстерү. Соңгы 3 елда төбәкара сәясәтне шактый көчәйттек. Патриотик тематиканың кирәкле булуы бик сөендерә. Россия Президенты куйган төп бурычларның берсе – тарихи дөреслекне саклау һәм яклау, – диде директор.

Аяна Шойгу Татарстанда патриотик проектларны тормышка ашырырга теләвен белдерде.

– Без сезнең тәкъдимнәрне хупларга һәрвакыт әзер. Татарстанда кызыклы һәм көчле чара үткәрәсебез килә. Бәлки, ул фестиваль булыр. «Геройлар мәктәпләре», «Мәгълүмат фронты» кебек проектларны сезнең республикада да тормышка ашырырга телибез, – диде ул. – Эшнең зур күләме тарихи территорияләрне үстерүгә бәйле. Әлбәттә, болар – һәйкәлләр, җимерелгән объектларны торгызу, махсус хәрби операциядәге егетләребезгә ярдәм итү, тарихи мәгърифәтчелек. Бу юнәлештә республика җитәкчелеге тарафыннан бик зур эш башкарылганын беләм. Җимерелгән объектларны төзекләндерүдә системалы эш итәргә тырышабыз. Һәйкәлләрне генә түгел, тарихи хәтерне дә торгызырга кирәк.

Узган елда республикада 17 истәлек тактасы урнаштырылган. Бу хакта «Россия хәрби-тарихи җәмгыяте»нең республика бүлегендә башкарма директор Александр Александров әйтте.

– Быел төп игътибар Советлар Союзы Геройларына һәм Дан орденнарының тулы кавалерларына истәлек такталары урнаштыруга булачак. Республикада 22 такта ясалды. Бишесе урнаштырылмыйча калды. Эш туктатылып торды, чөнки закон буенча алар ике телдә башкарылырга тиеш. Быел без бу эшне дәвам итәргә телибез, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

Сәламәтлек

БҮГЕННӘН КАЙГЫРТЫЙК

Сәламәтлек саклау министрының иртәсе нидән башлана? Саулыкны кайгыртудан, билгеле. Татарстанның сәламәтлек саклау министры Марсель Миңнуллин «Татарстан онлайн» проекты кысасында оештырылган «туры элемтә» вакытында шул хакта сөйләде. Моннан тыш министр сәламәтлек саклау тармагында ирешелгән уңышлар, быелга куйган максат-бурычлар белән дә уртаклашты.

Мавыгу

Сәламәтлек тармагының башында торган Марсель Миңнуллин һәр иртә 1,5 чакрым ара йөзә, кышын чаңгыда шуа икән. Кечкенәдән канга сеңгән гадәт дип атый ул моны.

– Совет чоры балаларында кечкенәдән спортка мәхәббәт тәрбияләделәр. Шуңа күрә бу мавыгуларым – балачактан килгән гадәт, – ди министр. – Һәркем үз сәламәтлеген кайгыртырга тиеш. Кызганыч, бүген арабызда диспансеризация кебек профилактик тикшеренүләрне кирәксенмәүчеләр шактый. Бигрәк тә 40–65 яшь аралыгында кешеләр моңа салкын карый. Берни дә борчымый бит, дип икешәр-өчәр ел табибка күренмичә яшәүчеләр бар. Ә бит күп кенә чирләр вакытында ачыкланса, алар дәвалауга да тизрәк бирешә.

Кадрлар

Марсель Миңнуллин сүзләренә караганда, Татарстанда табиблар уртача 104 мең сум хезмәт хакы ала. Шәфкать туташларына – 53 мең сум, санитарларга 38 мең сум түләнә. «Авыл табибы» программасы буенча авыл җиренә эшкә кайткан табиб исә 1,5 миллион сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акча ала. Моннан тыш, республикада табиблар Татарстан хөкүмәте грантларына да дәгъва кылырга мөмкин.

Узган ел Татарстанда эшләүче табиблар саны 409га арткан. Шулай да тармакта кадрлар кытлыгы бетми.

– Бу кытлыкны киметү максатыннан, укуын тәмамлаган яшь белгечләрне авылга кайтара башладык. Башкаладагы эре медицина оешмасына урнашырга теләсә, ул иң элек бер ел район җиренә кайтып эшләргә тиеш. Яшь белгечләргә яшәү өчен арендага торак бирелә. Аның өчен муниципалитет түли. Эштә дә яшь белгечне үзен генә калдырмыйлар. Ул үзенә билгеләнгән тәҗрибәле остаз белән киңәшләшеп эшли. Бер ел үткәч инде, шәһәргә китеп, үзе теләгән дәвалау оешмасында эшли, яисә үзе кайткан район җирендә төпләнеп кала ала, – дип ачыклык кертте министр.

Яңа объектлар

Узган ел республиканың беренчел звено тармагында 28 яңа объект төзелгән. Шуларның берсе Яшел Үзәннең Осиново бистәсендә ачылды. Икенчесе – Казан читендәге Дәрвишләр бистәсендәге балалар сырхауханәсе. Моннан тыш, «Сәламәтлек саклау» илкүләм проекты буенча районнарда 25 ФАП ачылган, 117 бина төзекләндерелгән.

– Якын арада Казандагы «Салават Күпере»ндә күппрофильле сырхауханә ачылачак. Балалар һәм олылар сырхауханәсе, травматология пункты, ашыгыч ярдәм хезмәте – барысы да бер бинада урнашачак. Баштарак ул 15000 кешегә исәпләнгән иде. Әмма ул 60000 кешегә хезмәт күрсәтәчәк. Бу – көненә 750ләп кеше кабул итәчәкләр дигән сүз, – ди Марсель Миңнуллин.

Аборт

Марсель Миңнуллин яңа вазыйфага килә-килешкә күтәргән мәсьәлә буенча эш быел да дәвам итәчәк. Сүзебез – хатын-кызның үз теләге белән ясала торган абортларны кисәтү турында. Билгеле булганча, әле күптән түгел генә Казанда Республика кризис үзәге төзелде. Ул, иң беренче чиратта, бала төшертү очракларын кисәтүне күздә тота. Шулай ук анда йөккә уза алмыйча азапланган хатын-кызлар да мөрәҗәгать итә ала.

– Хатын-кыз консультациясенә килеп, бала төшертергә теләвен әйткән хатын-кыз иң элек шушы үзәккә җибәрелә. Биредә махсус белеме булган, тәҗрибәле белгечләр эшли. Алар хатын-кызны бу фикереннән кире кайтарырга тырышачак. Алар авыр хәлдә калганнарга да ярдәм итәчәк, мәсьәләне чишү юлларын табарга булышачак, – ди министр.

Трансплантология

Соңгы елларда Татарстан трансплантология буенча да иң көчле төбәкләрнең берсенә әверелде. Республикада төрле әгъзаларны күчереп утырту буенча иң катлаулы операцияләр ясала. Марсель Миңнуллин сүзләреннән аңлашылганча, узган ел республикада барлыгы 213 әгъза күчереп утыртканнар. Мондый катлаулы операцияләрнең 72се – бавыр, 115е – бөер, 26сы йөрәккә ясалган.

– Алар, нигездә, бик авыр хәлдәге, яшәренә нибары 2–3 ай гына вакыт калган авыруларга ясала. Әгъзаны күчереп утырткач, алар тормышын яңабаштан башлый. Араларында хәтта бавырын күчереп утыртканнан соң йөккә узып, сау-сәламәт бала тапкан хатын-кызлар да бар, – дип шаккатырды министр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы Премьер-министры ярдәмчесе **Хәмәдишин** Дәүфит Закир улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **Почет ордены** белән бүләкләнде.

***

Илебез фәнен үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге һәм Россия Фәннәр академиясенә нигез салынуга 300 ел тулуга бәйле рәвештә Россия Фәннәр академиясе академигы **Синяшин** Олег Герольдович Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **Дуслык ордены** белән бүләкләнде.

***

Илебез фәнен үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге һәм Россия Фәннәр академиясенә нигез салынуга 300 ел тулуга бәйле рәвештә Россия Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы **Хәсәнов** Рөстәм Шамил улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **Пирогов ордены** белән бүләкләнде.

***

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Чүпрәле районы үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе табибы **Җәләлова** Гөлсинә Гарифулла кызына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Илебез фәнен үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге һәм Россия Фәннәр академиясенә нигез салынуга 300 ел тулуга бәйле рәвештә Россия Фәннәр академиясе академигы **Салихов** Кев Миңнулла улы Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә **Россия Федерациясе Президентының Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

***

Законлылыкны һәм хокук тәртибен тәэмин итүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсе башлыгы урынбасары – Идарәнең коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре бүлеге башлыгы **Рамазанов** Рамил Миргаяз улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының академик В.М. Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы **Әхмәтҗанов** Илгиз Илдар улы; республикада волейболны популярлаштыруга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Зенит» волейбол клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы командасы башлыгы (Казан шәһәре) **Баһаутдинов** Ринат Фәрит улы; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «АК БАРС Девелопмент» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең куркынычсызлык хезмәте башлыгы **Павлов** Юрий Ильич, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары **Хәйруллин** Рамил Камил улы, «Спорт сарае» дәүләт бюджет учреждениесенең трансформация һәм механикалаштыру хезмәте башлыгы **Якупов** Илшат Илгизәр улы, республиканың энергетика тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татэнерго» акционер җәмгыяте директорының электр энергиясен сату буенча урынбасары **Прытков** Владимир Викторович; күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен «Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе 17 номерлы колония-поселениесе» федераль казна учреждениесе башлыгы **Сәгыйтов** Раил Мәгъсут улы; республиканың фармация сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татхимфармпрепараты» акционер җәмгыяте генераль директоры **Ханнанов** Тимур Шамил улы; һөнәри эшчәнлектә ирешкән югары казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Гамәли оптика дәүләт институты» фәнни-җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятенең документлар белән тәэмин итү һәм контроль идарәсе башлыгы **Билалов** Ренат Харис улы; югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле фәнни-тикшеренү эшчәнлеге өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең беренче проректоры – фәнни эшчәнлек буенча проректоры **Таюрский** Дмитрий Альбертович; транспорт белән тәэмин итү өлкәсендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы прокуратурасының автомобиль йөртүчесе **Халиков** Габделкадыйр Габделхәй улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Лениногорск муниципаль районы буенча Ивановка авылыннан сигез бала анасы (аларның җидесе өч яшькә җиткән) **Псурцева** Мария Ивановна, «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге буенча биш бала анасы **Новикова** Алина Викторовна **Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

***

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры каршындагы башкарма аппаратының персонал белән эшләү идарәсе методология, аналитиканы һәм кадрларга идарә системасын үстерү бүлеге башлыгы **Глазкова** Фәридә Абрек кызы **«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале** белән бүләкләнде.

***

«Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте хезмәткәрләре: Шәмәрдән магистраль газүткәргечләр линия производство идарәсе электр энергиясе һәм су белән тәэмин итү хезмәтенең электр җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтеры **Кәримов** Фәнис Фәрит улына, «Түбән Кама газ» эксплуатация-җитештерү идарәсенең җир асты газүткәргечләре хезмәте җир асты газүткәргечләрен эксплуатацияләү һәм төзекләндерү буенча слесаре **Рәхмәтуллин** Илдар Минабетдин улына **«Татарстан Республикасының атказанган газ тармагы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«КАМАЗ» гавами акционер җәмгыятенең производствога идарә департаменты «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте баш диспетчеры **Әһлиуллин** Рөстәм Минсалих улына, «Казанның «Союз» тәҗрибә конструкторлык бюросы» акционер җәмгыяте баш технологы бүлегенең бюро башлыгы **Азаров** Иван Алексеевичка, «Казанның «Союз» тәҗрибә конструкторлык бюросы» акционер җәмгыяте сынау үзәгенең двигательләрне сынаучысы **Давыдов** Александр Николаевичка, «Ремдизель» акционер җәмгыяте двигательләрне һәм агрегатларны капиталь төзекләндерү цехының детальләрне механик эшкәртү һәм кимчелекләрен ачыклау буенча 1 номерлы участогы автомат линияләре һәм агрегат станоклары көйләүчесе **Ишимов** Виктор Николаевичка, «Ремдизель» акционер җәмгыяте җитештерүнең сыйфатын тәэмин итү һәм башлангыч контроль хезмәтенең двигательләрне һәм агрегатларны капиталь төзекләндерү цехы техник контроль бюросы станоклар һәм слесарьлык эшләре контролеры **Нуриева** Гөлфия Салих кызына **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте автомобиль заводының 2 номерлы җиһазларны төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү цехының электр җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтеры **Ахмаев** Георгий Гаяз улына, «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыятенең «Алабуга электр челтәрләре» филиалы баш инженерының электр бүлү челтәрләре буенча урынбасары **Гыйззәтуллин** Ринат Шәрифҗан улына, «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыяте «Буа электр челтәрләре» филиалының изоляция һәм артык көчәнештән саклау хезмәте төп челтәрләр җиһазларын сынау төркеме әйдәүче инженеры **Усманов** Рамил Рәшит улына **«Татарстан Республикасының атказанган энергетигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Фидакарьлек үрнәге

Аның белән мин телефон аша гына таныш идем. Газета вакытында килеп җитмәгәч, шалтыратып, сәбәпләрен белешүдән башланган ул танышлык барысы шундый биш-алты хәбәрләшүдән дә артмады кебек. Ә бит ул дәшкән иде. Кул биреп бер тапкыр булса да күрешмәвем, якыннанрак танышмавым өчен соңгы берничә елда үземне ничә тапкыр битәрләгәнмендер…

Бүгенге сүз данлыклы «Звезда Поволжья» газетасы нәшире Рәшит Әхмәтов турында иде. Исән булса, шушы ел башында ул үзенең 70 яшьлек юбилеен билгеләп үткән, гомеренең төп эше булган шул басманы чыгарган, затлы төп мәкалә – «передовица»лары белән зыялы халыкны һаман да сөендергән булыр иде. Кызганыч, ковид дигән зәхмәт аны да читләтеп үтмәде – 2020 елның көзендә Рәшит абый бакыйлыкка күчте.

Аның вафаты хакындагы хәбәрнең кайсы тарафтан килеп ирешкәнен инде хәтерләмим. Сентиментальлек белән артык аерылып тормаган бу юллар авторы шул мизгелдә күз яшьләрен тыя алмады, дию генә аз. Ул үлем мине тетрәндерде, үксүгә җиткерде, туганымны югалтудан да авыррак булды. Ул шулай булырга тиеш иде дә…

Газетаны һәрчак көтеп алсам, соңгы битенә чаклы җентекләп укысам, үзен бик хөрмәт итсәм дә, әрсезләнеп, ешрак шалтыратырга, редакциягә әверелгән фатирына азга булса да сугылырга, әйткәнемчә, һич тә кыймадым. Бары икебезнең дә бер үк техник вузны тәмамлаган булуыбыз, шәхес масштабы нык аерылса да, аның да, минем дә язу эшенә соңлап булса да алынуыбыз, аналитик язмаларга мөкиббәнлегебез белән эчтән генә горурланып йөрдем.

Рәшит Әхмәтов. Нәшир һәм мөхәррир. Ул чыгарган, зыялы кавем «ябышып» укыган, олы форматлы мөхтәрәм газета. Һәрдаим актуаль проблемаларны күтәргән, вакыйгаларга тирән анализ ясап килгән меңгә якын сан. Татар телен белмәгән милли җанлы меңләгән милләттәшебезнең дә Рәшит абый биреп килгән рухи һәм интеллектуаль азык белән туенып торуы. Ни кызганыч, андый хәзинәдән без бүген мәхрүм. Шулай да өмет бөтенләй сүнмәгән – аның эшен, шактый яшь булуына да карамастан, улы Руслан дәвам иттерә. Кайчан да булса ул да әтисе югарылыгына күтәрелер, басманы да күтәрер, дигән ышаныч та исән, яши. Уңышлар телик без аңа.

Рәшит Әхмәтовны Татарстан журналистикасы тарихында, республика тормышында якты эз калдырган шәхес дию арттыру түгел. Фикер иясе, интеллектуал, сәясәтне, иҗтимагый вазгыятьне генә түгел, хәтта музыка белән театрны да тирәнтен аңлаган, теләсә кайсы спектакльне сүтеп җыя алган затның юклыгы үзен бүген нык сиздерә. Республиканың Журналистлар берлеге рәисе, ТНВ каналы җитәкчесе Илшат Әминовның Әхмәтовны «Татарстан журналистикасының чын рыцаре, куркусыз һәм дәгъвасыз зат» дип атаганы истә. Чыннан да татар милләтен, республика ихтыяҗларын аяк терәп яклаган русча газета чыгару аңа бер дә җиңел булмады. Газетаны берничә тапкыр ябарга җыенуларын, нәширнең суд юлларын таптавын да искә алганда, Рәшит әфәндене журналистикада бүген сирәк күренеш булган батырлык үрнәге, дию дә бик дөрестер.

Әйе, киң эрудиция, ачык һәм аңлаешлы, ныклы гражданлык позициясе өстенә фидакарь дә зат иде ул. Андыйларга мин һәрдаим сокландым һәм сокланачакмын. Фидакарьлек бүген дефицитта, ә яраклашу, шул сыйфат китергән тук тормыш исә трендта, модада. Күпләргә танылу, карьераның, кәнәфинең проблемасыз булганы, яхшы дивидендлар китереп торганы кирәк. Тик, шөкер, һәммә кешегә дә түгел. Тормышта күпләр күрергә теләмәгән яисә күрмәгән башка кыйблалар, кыйммәтләр дә бар бит әле. Шул тарафларга йөз белән борыласы, «кәҗәсеннән мәзәге кыйммәтрәк» дип яшисе иде дә бит…

Җитештерүдә хезмәт куйганда төрле структур берәмлекләрне җитәкләргә туры килгән тәкъдирдә, «генерал буласы килмәгән солдат – солдат түгел», дисәләр дә, директор, гендиректор ише олы вазыйфаларга ия булу хакында ялгыш та хыялланмадым, дип әйтә алам. Бу хәл, ихтимал, башка төр «генерал»ларга, алар сайлаган юлга мөкиббәнлек белән аңлатылгандыр. Фикер һәм гыйлем ияләренә, техник юнәлеш булсын, гуманитар булсын, ил-көнгә нидер биреп, китереп торган галимнәргә, иҗади шәхесләргә, төрле фидакарь затларга соклanудан, алардан ак көнләшү белән көнләшүдәндер. Чөнки ни генә әйтмә, җәмгыятьне, без яшәгән тирәлекне яхшырак, яктырак итүчеләр дә – төрле рангтагы чиновник, башлыклар, хәтта президентлардан да бигрәк, нәкъ шул алда саналган кешеләр бит.

Рәшит Әхмәтов куркусыз, үз газетасы тирәсенә төбәкнең интеллектуаль элитасын җыя алган, басмасында төрле, күп чакта капма-каршы фикерләргә дә урын биргән нәшир һәм журналист иде. Аны журналист дип атау бик урынлы да түгел. Ул, кайберәүләр билгеләгәнчә, чын мәгънәсендә мәгърифәтче, халык сәясәтчесе, милләтнең идеологы, татар иҗтимагый фикеренең маягы да булды кебек. Шунысы үкенечле: ул уникаль кеше белән бергә тулы бер дәвер – безнең үзбилгеләнешкә омтылган романтик чор да тарихка күчте. Демократия «дулаган», кеше, аның ирек-хокуклары турында зурдан кубып сөйләшкән чакларда Рәшит Әхмәтов милләт хокукларын алардан ким күрмәгән, алар өчен көрәшергә чакырган зат була алды.

Газетаның үзем алган номерлары әле бүген дә исән. Һәр елныкы аерым папкада. Еш булмаса да папкаларны ачам, аерым саннарның инде онытыла башлаган баш мәкаләләрен укыйм. Ул язганнар бүген дә бик актуаль. Нәшир-редакторны соңгы юлга озатканда кайсыдыр оратор әйткән тәкъдим – Әхмәтовның барлык мәкаләләрен бергә җыеп, саллы китап чыгару өстендә эшли башлаганда да ярар иде бүген. Ул эш башкарылса, без 1990 нчы еллар татар ренессансы тарихы, 2000 нче еллардагы чигенешләр хронологиясе дә булдырылды, елъязма рәвешен алды, дип әйтә алыр, язмалар авторына шул рәвешле һәйкәл дә куяр идек…

КАЛӘМ ОЧЫНДА – ЗАТЛЫ СҮЗ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Юбилей

Якташыбыз, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы, «Ватаным Татарстан» газетасы журналисты Риман Гыйлемхановның юбилеена багышлап, Арчада үткәрелгән искиткеч матур кичә турында язманы Татарстан халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Зиннур Мансуров сүзләреннән башлыйсы килә. «Дөньяда Арча җирлеге кадәр күренекле кешеләр биргән башка төбәк юк!» – диде ул.

Риманның әдәбиятка килүе дә юкка түгел. Без аның белән университетта бергә укыдык, туган авылы Субаш Атыга да кайта идек. Әтисе Солтан абыйны, әнисе Дания апаны күреп белә идем. Әнисе – Тукайның туганы, әтисе Солтан абый – шагыйрь, китаплары чыккан. Икесе дә – педагоглар. Шундый гаиләдә үскән Риман кулына ничек каләм алмасын! Бүген дә бал корты кебек эшли ул. Кулына таяк тотып йөри башлагач, тагын да күбрәк йөри шикелле…

Арча үз талантларын барлый, хөрмәтли, кичә дә – шуның ачык мисалы. Әлеге кичәне уздыру тарихы үзе дә кызыклы. Юбилей җитәр алдыннан Риман миңа телефоннан шалтыраткан иде. «Ватаным Татарстан»ны кулга алуга, мин Риман Гыйлемханов, Рәшит Фәтхрахманов язмаларын эзләп алам. Якташлар булган өчен генә түгел. Туфан Миңнуллин да: «Риманның язмаларының һәммәсендә «маймыл»ы була», – дигән бит. Гади, кызыклы, мавыктыргыч, аңлаешлы, үтемле итеп яза Риман.

Алып баручыларның берсе Рамил Мөхетдинов: «Риман әфәнде бик тыйнак кеше, «Артык мактаудан оялам, йөзем кызара», – дияргә ярата. Бүгенге кичәне дә ул хатирәләрне яңартып, бер сөйләшеп утыру итеп күзаллавын әйтте. Тик бүгенге юбилей кичәсендә мактаулар булмый калмас!»

– Риман абый – республика дәрәҗәсендә танылган, бик мактаулы, чын кеше! – дип башлады сүзен район башлыгы Илшат Нуриев. – Мин кешенең тормышы – зур проект дип уйлыйм. Һәр кеше аны үзенчә тормышка ашыра. Риман абый бу яктан бик бәхетле. Мин аның белән сирәк очрашам, әмма озаклап сөйләшәбез. Халык өчен янып, татар милләте турында кайгыртып, район өчен тырышып яши торган якташыбыз ул.

«Татмедиа» агентлыгы җитәкчесе урынбасары Илдар Миргалимов: «Без Риман абый белән почти якташлар, – диде. – Минем әни – Субаш Атыдан ерак булмаган Югары Аты авылыннан. Риман абыйның әтисе Солтан абыйны да бик зыялы кеше иде, дип сөйлиләр. Ул мәктәп директоры булган, кешегә авыр сүз әйтә белмәгән. Нәрсәдер килеп чыкканда: «Их, чибәр егет, Мостафа!» – дия торган булган. Бу сүзнең нәрсә аңлатканын аңлап бетермәсәләр дә, башка андый ялгышлык кабатланмаган. «Ватаным Татарстан»да эшләгән вакытымда Риман абыйның да авыр сүз әйткәнен ишетмәдем, ул аңлатуның башка юлларын куллана иде. Тере легенда инде ул, һәр кешене үз итә белә. Сәер гадәтләре бар, җырлап җибәрә. Башка кешеләргә охшамаган, шуның өчен яратабыз да аны. Редакция коллективында өч буын булу – үзе бәхет, татар матбугатының традицияләре буыннан буынга тапшырылып килә».

– Риман – мине әйдә, әйдә, диеп сәхнәгә алып чыккан кеше, – диде язучы-сатирик, автор-башкаручы Алмаз Хәмзин. Риман белән бергәләп концертлар куеп йөргән вакытларны, кызыклы вакыйгаларны бергәләп искә алдылар.

Татарстан Дәүләт телерадиокомпаниясенең милли тапшырулар хезмәте җитәкчесе Миңназыйм Сәфәров: «Аллаһы Тәгалә кешене Җир йөзенә ниндидер миссия башкару өчен китерә, – диде. – Журналистика – Риман абый өчен яшәү рәвеше, диагностика. Без аның белән «Татарстан яшьләре»ндә, аннан соң «Ватаным Татарстан»да озак еллар бергә эшләдек. Укучыга бүген затлы сүз кирәк, аңа ихтыяҗ зуррак. Риман абый сүзен үлчәп сөйли, гаиләдәге бабай шикелле абруйга ия».

«Ватаным Татарстан» газетасы мөхәррире урынбасары Зөлфия Хәлиуллина: «Кешене туган җирендә шулай хөрмәтләүләре – зур бәхет. Район җитәкчесе Илшат Габделфәртовичка зур рәхмәт. Риман абыйны коллектив та, газета укучылар да бик ярата. 50 ел шушы хезмәткә тугрылыклы кеше, ул безгә бик кирәк», – диде.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Әсхәт Хисмәт Риман Гыйлемхановны 1976 елдан телестудиядә эшләгән вакытыннан белүен әйтте. «Җор телле, тыйнак кына кеше. Аннан газетада эшли башлады, ә мин – бик игътибарлы укучы. Бер сулышта укыла торган, йөрәккә ятышлы, күңелгә керә торган әйберләр яза бу. Аннан соң күрешеп танышырга туры килде, дуслар булып яшибез».

«Казан утлары» журналының баш мөхәррире, якташыбыз Рөстәм Галиуллин 120 мең тиражы булган «Татарстан яшьләре» газетасыннан Риман Гыйлемханов язмаларын мәктәп елларында ук шаккатып укыганын сөйләде:

– Ул язмаларында безнең Наласа авылыннан ерак булмаган Субаш Атының теге башында яшәгән Шәймулла абыйның, бу башында яшәгән Фәгыйлә апаның сүзләрен китерә, мин андый акыллы кешеләр ничек Субаш Атыда гына икән, дип аптырый идем. Мотоциклга утырып, шул авылга барасым да килде. Үзем редакциядә эшли башлагач кына андый кешеләрнең һәр авылда бар икәнлегенә төшендем.

«Өйрәтәләр мәктәпләрдә» дигән җырны кем генә җырламый? Ә аны русчадан татарчага тәрҗемә итүченең Риман Гыйлемханов икәнлеген шушы кичәдә белдем. Күпме очрашып, сөйләшеп торабыз, берәү булса күкрәк сугып мактаныр иде. Ә ул – ләм-мим! Мин үзем дә яратып тыңлыйм бу җырны, безнең оныкларга нинди бүләк ясаган Риманыбыз! Әсхәт Хисмәт шундый матур итеп җырлап та күрсәтте әле!

Җыр дигәннән, кичәдә яңгыраган җырлар да күңел кылларына тиярлек иде. Риман Гыйлемханов, Алмаз Хәмзин, Әсхәт Хисмәт «Арча» җырын бергәләп башкардылар. Арчаның үз сандугачлары Расих Галимҗанов, Сөмбел Заһидуллина, Дамир Гасыймов, гармунчылар чыгышы матур бәйрәмне тагын да ямьләндерде.

Ильяс ФӘТТАХОВ

Мәңгелек мәхәббәт

Туган көн бәйрәмен уздырып, Арчадан Казанга кузгалгач, юл буе туган як турындагы җырларны искә төшереп, күңелдән барлап кайттым. Бихисап икән алар. Сан буенча мәхәббәт җырлары беренче урындадыр дип уйлап йөргән идем, ялгышканмын.

Әле аның мәхәббәт хисеннән ташыганнары да еш кына туган якны сагынуга кайтып кала. Берничә мәртәбә өйләнүчеләр, берничә мәртәбә кияүгә чыгучылар бар, ә туган як бер генә, димәк, ул – мәңгелек мәхәббәт.

Туган җир, туган нигез «тормыш» дигән гаҗәеп дөньяга сәфәргә кузгалу ноктасы кебек. Күпмедер еллар һәм юллар узгач, без яңадан шул ноктага әйләнеп кайтабыз. Шул әйләнгеч юлны күпме вакыт һәм ничек узуыбыз туган нигездән нинди көч-куәт, рухи байлык алып китүебезгә бәйле. Гомер буе сагындыра туган як, сагыну хисе еллар узган саен көчәя, кеше хәтта мәңгелек тынычлыкны да туган җирдә табарга тели.

Миңа, Тукай рухын эзләп, Казахстанга һәм Кытайга сәфәр чыгарга туры килде. Чит мәмләкәттәге, бигрәк тә Кытайдагы милләттәшләр белән очрашканда, бездән (өч журналист кыз һәм мин) иң элек: «Сез Татарстанның кай төшеннән?» – дип сорыйлар иде. Башта моңа сәерсендек. Ә баксаң, кардәшләребез безнең арада якташлары бармы-юкмы икәнен белергә теләгәннәр. Аралашкан кардәшләребез – Кытайда яшәүче татарларның инде өченче, дүртенче буыннары, әмма ата-бабаларының туган ягы, андагы тормыш аларны бүген дә кызыксындыра икән. Гаҗәп хәл: алар бит бабалары туган Арча, Әтнә, Әлмәт, Апас якларын гомердә дә күрмәгән, әмма күңелләрендә туган якка мәхәббәт хисләре саклыйлар. Күрмәгән, белмәгән җирләрне дә шулай сагынып була икән, валлаһи. Бабалары: «Туган туфракка кайтып үлсәм, миннән дә бәхетле кеше булмас иде», – дип әйтә торган булган. Бу сүзләр, васыять кебек кабул ителеп, буыннан-буынга күчә килгән.

Мин Арчама җай чыккан саен кайтам. Әти-әнием инде вафат. Зиратка кереп, аларның кабере янында дога укыр өчен, авылдашларымны, газиз күршеләремне, балачакта су коеныргa төшә торган Мөхәммәтҗаннар тыкрыгын күрер өчен кайтам мин авылга.

Туган якка мәхәббәт, нәкъ кешеләрнеке кебек ике яклы булырга, без бер-беребезнең хәлен белеп торырга, кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тиеш, дип уйлыйм. Арчама кайткач, якташларымның күркәм гамәлләрен күреп куанам, хисләремне язмаларым аша башкаларга җиткерәм. Кайчак миңа: «Үз районың турында гел мактап язасың», – дип төрттерәләр. Мин: «Сез дә үз якларыгызда матурлыкны күбрәк күрергә тырышыгыз», – дим. Каршы әйтмиләр тагын. Туган көнем уңаеннан оештырылган бәйрәмгә дусларым да кайткан иде. Аларның сокланып: «Арча – Арча шул инде ул!» – диюләренә куандым. Тик менә сәхнәгә чыгып, мине мактап сөйли башлагач, бераз кыенсынган идем үзе. Күңелгә: «Нүжәли мин шундый яхшы егет инде?» – дигән шик тә керде. Ике арада югалып та калдым. Ярый, сөйләнәсе сөйләнгән инде, мактау сүзе «аванс» булыр, дип үземне тынычландырырга маташтым. Шул ук вакытта бер башка үсеп тә киткәндәй булдым. Ә дуслар алдында: «Карт кешенең юктан да күңеле була инде», – дип шаярттым. Ярый әле туган якка кайтканмын. Арчага киткәндә, баш мөхәрриребез Гөлнара Сабирова Туфан Миңнуллинның: «Кешене туган җирендә зурламасалар, ул беркем түгел», – дигән сүзләрен искә төшергән иде.

Туфан абый исә Кама Тамагы районындагы туган авылы – Олы Мәрәтхуҗаны дөньяның иң гүзәл шәһәрләренә дә алыштырмады. Аның: «Парижыгыз үзегезгә булсын!» – дигән сүзләрен бүген дә хәтерлим әле. Олуг әдибебез туган ягы, туган авылы өчен яшәде, татар авылларының милләт сагында булуларын, телебезне, яшәү рәвешебезне, иң күркәм йола-гадәтләребезне саклап тотуларын белә иде ул. Бүген Олы Мәрәтхуҗада аны фамилиясе белән атамыйлар, «безнең Туфан» дип кенә йөртәләр.

Туган якны үз итсәк, ул да безне яратыр, якташлар «безнең фәлән» дип дәшәр. Туган яктан, авылдан йөз чөерсәк, орлыклары өлгереп тамырыннан аерылган дала үләне дүңгәләк кебек җил уңаена тик тәгәрәп йөрербез.

Яшәсен туган як, туган нигез, туган туфрак. Рәхмәт, якташларым!

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Кайсыгызның кулы җылы?

ЯШӘРГӘ ӨЙРӘНҮ

Сәламәтлегендә акыл ягыннан тайпылыш булган сабыйларны үстерүче ата-ананы ниләр борчый, аларга ничек ярдәм итәргә? Халыкка комплекслы социаль ярдәм күрсәтү үзәгендә әнә шул хакта сөйләштеләр. Очрашуда Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова да катнашты.

– Татарстанда психик тайпылышы булган 90 меңнән артык кеше яши. Шуларның 26 меңе Казанда көн күрә. Аларның яртысы яшьләр һәм балалар, – ди Эльмира Зарипова. – Без психик тайпылышлары булган балаларны мөстәкыйль тормышка җайлашырга өйрәтергә тиеш. 2022 елда Татарстан «Менталь сәламәтлек» дип аталган иҗтимагый проектны тормышка ашыра башлады. Проект Идел буе округында 2019 елдан бирле эшли. Ул сабыйлардагы авыруларны иртәрәк ачыклау, мондый диагнозлы кешеләрнең исемлеген булдыру һәм аларны мөстәкыйль тормыш алып барырга өйрәтү өчен башкарыла.

Психик тайпылышы булган кешеләрне, ничә яшьтә булуга карамастан, эшкә өйрәтү, кайчакта хәтта эшкә урнаштыру мөмкинлеге дә бар, ди министр. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, инвалидларны тормышка өйрәтер өчен, көндезге бүлекләр ачарга кушкан. Бу бүлекләр Татарстанның һәр районында бар.

Министр «Идел» тернәкләндерү үзәгендә нәкъ менә шундыйларны өйрәтүләрен әйтә.

– Биредә авыруларга барлык мөмкинлекләр тудырылган. 18 яшьтән 30 яшькә кадәрле кешеләр биредә эшкә өйрәнә. Тагын шунысы да бар: авыру бала үстерүче әнигә дә ял кирәк. Без бу балаларны 3 айга алып китеп, ашарга пешерергә, кибеткә йөрергә генә түгел, шәхси гигиенага кадәр өйрәтәбез. Кайчак әниләре балалары өчен бик борчыла. Көнгә әллә ничәшәр шалтырата. Соңыннан рәхмәт әйтәләр, – ди Эльмира Зарипова.

Казанда яшәүче Елена Шәкүрованың кызы Аринага 23 яшь икән инде. Көн саен үзәккә киләләр.

– Арина коррекцион мәктәптә укыды. Әмма мондагы кебек беркайда да өйрәтмәделәр. Мин олыгаям, Арина миннән соң да калачак бит. Менә шул вакытка әзер булсын дип тырышам. Биредә ул бөтенләй үзгәрә. Кайчак төннәрен ятам да, әгәр бу үзәкне япсалар, нишләрбез, дип борчыла башлыйм. Безнең бүтән барыр җиребез юк. Әнә шуңа да үзәкнең гел эшләвен телим.

Баксаң, балаларны гына түгел, әти-әниләрне дә укыталар икән. Бу «Демография» илкүләм проекты кысасында «Озак вакытлы ярдәм» проекты нигезендә тормышка ашырыла.

Очрашуга килгән ата-аналарның министрга сораулары да бар иде. Кемдер инвалид баласына фатир алу тәртибен белми, кайберәүләр мондый үзәкләргә йөртү тәртибен сорый. Эльмира Зарипова һәрбер сорауга җавап бирде:

– Әти-әниләр уңайсызланып тормасын иде. Барлык мөмкинлекләрне дә файдаланырга кирәк. Соңгы елларда җәмгыятьтә инвалидларга караш үзгәрде, – ди ул. – Республика күләмендә күп кенә чаралар уздырыла. «Абилимпикс» бәйгесе аларның һөнәри осталыкларын күрсәтергә мөмкинлек бирә. Төрле бәйгеләр, фестивальләр аларны тагын да берләштерә. Хатын-кызлар өчен уздырыла торган «Татарстан энҗесе» бәйгесе дә өмет бирә, башкалардан ким түгеллекләрен күрсәтә. Шуңа күрә актив булырга, оялмаска кирәк. Без исә үз юнәлешебез буенча кулдан килгәннең барысын да эшләрбез.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ТАТАРСТАН — КАЗАНЫШ ҖИРЕ

ҮЗЕБЕЗГӘ КАЙТУ

«МӘДӘНИЯТ» МӘДӘНИЯТНЕ НИЧЕК ҮЗГӘРТТЕ?

Әлеге һәм башка сорауларга җавапны «Волга» экспертлар клубының чираттагы утырышында эзләделәр. Бу юлы ул Татарстанда «Мәдәният» илкүләм проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәләренә багышланган иде.

Шуңа игътибар иттек: әлеге фикер алышу монда фәлән мәдәният йорты ачылды, тегендә фәлән китапханә яңартылды ише фактлар һәм саннарга нигезләнмәде. «Мәдәният» проекты кысасында башкарылган эшләр халыкка рухи яктан ничек тәэсир итте? Без кая таба бара идек тә кая таба борылдык? Чарада әнә шул сорауларга җавап эзләделәр.

«Мәдәният»тән башлыйк. Россия Президенты Владимир Путин тарафыннан гамәлгә куелган әлеге илкүләм проектның Татарстан өчен төп нәтиҗәләре нинди? Бу хакта республиканың мәдәният министры Ирада Әюпова сөйләде.

– Илкүләм проектлар турында сөйләгәндә, еш кына инфраструктурага игътибар күбрәк бирелә. Билгеле, «Мәдәният» проекты кысасында да бу җәһәттән эш күп башкарылды. Ләкин төп нәтиҗә – төзелгән һәм төзекләндерелгән биналар саны түгел. Төп нәтиҗә – ул биналарда эшләүче, юк, яшәүче кешеләргә таба борылу. Алар булмаса, ул гаҗәеп матур биналардан ни файда? Һәм тагын бер мөһим нәтиҗә – халыкка кирәк булуыбызны тою. Әйтик, күп кенә театрлар ел дәвамында куела торган спектакльләр санын ике мәртәбә арттырды. Чөнки кеше билет юклыктан зарлана! Төп бәя – әнә шул, – диде ул.

Татарстанда яшәүчеләрнең **67 проценты** соңгы биш елда үзләренең мәдәни тормышында уңай үзгәрешләр булуын әйткән. Сораштыруда катнашучыларның **70 проценты** бу үзгәрешләрнең күпчелеге «Мәдәният» илкүләм проекты нәтиҗәсе булуын белә.

Татарстандагы иң яхшы кайтавазлар җыйган төп 3 урын

1. Казан Кремле.
2. Зөя утрау-шәһәрчеге.
3. Милли китапханә.

Иң яхшы кайтавазлар җыйган Татарстан фильмнары

1. «Ядәч! Истә!»
2. «Микулай».
3. «Бибинур».

Татарстанда яшәүчеләр нәрсә белән горурлана?

- **Мәдәни объектлар**
Иң еш аталганнары – Казан Кремле, Милли китапханә, Болгар шәһәре.
- **Күренекле шәхесләр**
Иң еш аталганнары – Муса Җәлил, Рудольф Нуриев, Габдулла Тукай, Иван Шишкин, Бакый Урманче.

*Әлеге мәгълүмат «Диалог Регионы» оешмасының Татарстандагы бүлеге «Татарстан – казанышлар җире» проекты белән берлектә уздырган социологик тикшеренү нәтиҗәләренә нигезләнгән.

Без әле кая барабыз?

Бу җәһәттән дә сүзне Ирада Әюповага бирик.

– Моңарчы без «Россиядә җитештерелмәгән һәр нәрсә – модада» дип уйларга өйрәнгән идек. Ул бар нәрсәгә дә кагыла иде: фильмнар да, әдәби әсәрләр, спектакльләр һ.б. Импортка дан җырладык. Бу соңгы елларда гына түгел, бәлки, гасырлар буе формалашкан фикер булгандыр. Теләсә нинди үзгәреш парадигма алыштырудан башлана. Әйтик, хәзер без Россиядә төшерелгән фильмнарны күбрәк карый башладык. Киемнәребез дә үзебездә тегелгән… – дип сөйләде министр.

Бу үзгәрешнең төп кыйммәте – үзебездәге талантларны күреп, аларга ярдәм итү. Әюпова әнә шул фикердә. Аларны дөнья күләмендә көндәшлеккә сәләтле итеп тәрбияләргә кирәк. «Бездә менә шундый зур максат булырга тиеш», – диде ул.

Ачышлар елы

Мондый рухтагы сөйләшүне иң зур көчләрнең берсе – кино өлкәсеннән башка күз алдына китерү кыен, билгеле. Фикер алышырлык сәбәп булгач, бигрәк тә. Узган ел Татарстанда төшерелгән ике фильмның киң прокатта күрсәтелүен истән чыгармыйк, диюебез. Ә бездә җитештерелгән кинопродукт дөнья масштабында көндәшлеккә сәләтлеме? Читтә аңа ихтыяҗ бармы? Безнең киноны читкә дә чыгарып буламы? Бу сорауларга режиссер һәм продюсер Илшат Рәхимбай җавап бирергә тырышты.

– Миңа калса, Татарстандагы кино өлкәсе өчен 2023 – ачышлар елы. Узган ел без төшергән «Микулай» киң прокатка чыкты. Озак та үтмәде, Байбулат Батулланың «Ядәч! Истә!» фильмы да дөнья күрде. Татарстанда җитештерелгән кинопродуктка карата чын мәгънәсендә ихлас кызыксыну сизелде. Һәм бу кызыксыну, игътибар вакытлыча түгел дип уйлыйм мин. Ул күпкә тирәнрәк, – диде ул. – Минемчә, мондый фильмнар, мондый вакыйгалар бары тик Татарстанда һәм Татарстан кешеләре белән генә төшерелә ала. Башкалар безгә хас тарихны тиешле дәрәҗәдә сөйли алмаячак. Һәм ул тарих, хикәяләр бездә генә калырга тиеш түгел.

Сан

2023 елда «Мәдәният» илкүләм проектын гамәлгә ашыруга Татарстанда **1,5 млрд** сум акча каралган булган. Ел дәвамында җәмгысы **35** мәдәният оешмасы төзелгән һәм төзекләндерелгән.

Башка төбәкләр белән дә шул ук хәл. Һәр җирлекнең дөнья белән сөйләшә алырдай үз теле бар. Татарстанда да дөнья белән элемтә-диалогка керү өчен мөмкинлек зур.

Кайда тусаң, шунда…

Көндәшлек турында сүзне дәвам итсәк, безнең кайбер сәләтле иҗатчыларны читтә яхшырак та беләләр әле. Кызганыч, диикме, бәхеткәме?.. Әйтик, Татарстанның «Evolution» креатив агентлыгын хәзерге вакытта Дагыстан, Чечня, Ингушетиядә көтәләр.

– Шушы арада гына Түбән Новгородта балалар хастаханәсе ачылды. Аның концепциясен безнең оешма булдырды. Ачылыштан соң хезмәттәшләрем бер видеоязма җибәрә. «Яңалыклар» тапшыруын алып баручы: «…һәм дизайн проект эшләү өчен махсус рәвештә татар дизайнерлары чакырылды…» – ди. Моны ишеткәч, нәрсә уйларга да белмәдем. Әмма бик зур горурлык хисе кичердем. Югыйсә мин бит Мәскәүдә дә кала ала идем. Ул очракта без федераль агентлык дәрәҗәсендә булыр идек. Әмма мин «кайда тудың – кирәгең шунда чыгар» фикеренә тугры, – дип сөйләде агентлык җитәкчесе Арина Судакова.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Атынгыч

Атынгычта атынганыгыз бардыр инде? Җирдән кинәт кенә этелеп китәсең дә алга омтыласың, билгеле бер биеклеккә менеп җиткәч, кирегә чигәсең, аннан тагын алга… Сүз белән аңлатып та булмый бугай, әллә нинди бер тылсымы бар аның. Тизлегеңне арттырган чакларда бигрәк тә. Аякларыңны тиздән җыеп артка чигенәсең… Чигенәсең дию бармый монда. Бу чигенү түгел, бу – аз гына арткарак китеп, көч туплау гына. Хәтта чигенсәң дә, син өскә күтәреләсең, гайрәт җыясың һәм бар кодрәтеңә талпынып, аякларыңны турайтып җибәрәсең. Атынгыч алга ташлана. Каршыңа очкан Җир шарына барып бәрелердәй булып киләсең дә тагын югарыга омтыласың. Җир шары аста кала. Йөзеңә җил бәрелә. Чәчләрең тузгып киткәндәй була. Бер мизгелгә генә тизлек меңләтә арткан шикелле тоела. Син очасың…

Билгеле бер биеклеккә, ераклыкка җиткәч, әлбәттә, тагын кирегә китәсең. Шул ук тизлек белән кабат элекке ноктага кайтасың. Тик артка барганың сизелми. Сизелсә дә, ул кирегә китү кебек тоелмый, чөнки ул мизгелдә син тагы да ныграк талпыну, тизлегеңне һәм биеклегеңне арттыру турында уйлыйсың. Ә алга бару турында уйлап узган гомер ул чигенү дә, җиңелү дә, артка бару да түгел. Бу бары тик… Белмим инде ни дип атарга да. Үз урыныңны билгеләү, киләчәккә омтылышыңны көйләү мизгеле инде ул. Изге мизгел.

Атынгычта артка киткән чагың сизелми. Шуңа син гел алга барган шикелле тоеласың. Әгәр атынгычың биегрәк, бавы да озынрак булса, бу халәт тагы да ныграк көчәя, бөтен тылсымы ачыграк төсмерләнә. Аяк астындагы җир дә гади урын түгел, ә Җир шарының үзе сыман тоела. Син һәрвакыт алга барасың, син гел югарыга күтәреләсең. Син гел югары тизлектә җилдерәсең. Әнә ич хәтта җил дә битләреңне чеметтерердәй итеп килеп бәрелә дә каядыр чәрдәкләнеп оча. Син җилләрне ертып җилдерәсең. Җилләрдән дә җитезрәк булып…

Менә шундыйрак тойгы кала. Атынгычта тойгы гына өстенлек итә, монда хисләр генә үткенләнә. Монда синең бар булмышың хис-тойгыдан тора. Ә уйлар каядыр югала. Уйланып торырга вакытың юк. Уйлар кирәк тә түгел. Аңа бернинди мохтаҗлыгың юк. Синең барыр юлың билгеле, кылыр хәрәкәтең дә ап-ачык: аз гына артка китәсең дә алга ташланасың. Син монда уйлардан өстен.

Атынгычтан төшкәч кенә уйлар кире кайта. Югарыда сине куып тоталмыйча интегеп йөргән җирләреннән сөенешеп киләләр дә җилкәңә менеп атланалар. Уйлар кайтып җитү белән баягы ашкынулар, канатлы хисләр юкка чыга. Җирнең тарту көче шикелле чынбарлык суырып ала да үз урыныңа кабат беркетеп куя. Ә чынбарлык син уйлаганча, син теләгәнчә үк түгел икән…

Беренчедән, кайчаннан бирле алга томырылсаң да, битләреңә бәрелгән җилләр тизлегенә кинәнсәң дә, син беркая да китә алмагансың. Элек кайсы урында булсаң, әле дә шунда калгансың. Моңа ышанасы килми. Алай булырга тиеш түгел бит инде! Син бит шулкадәр озак җилдердең, хәтта уйларың да куып тота алмас тизлектә булдың. Ә үзең… Югыйсә ул вакытта шул тизлектә Җир шарын әллә ничә кабат урап чыгарга тиеш кебек идең бит.

Икенчедән, син бернинди биеклеккә дә күтәрелмәгәнсең. Нинди оста итеп талпындың бит инде югыйсә… Ул талпыну белән син галәмгә дә чыга алган булыр идең. Әнә ич, башкалар да атынгычта, кайберләре синнән дә югарырак күтәрелә, хәтта гәүдәләре дә күз алдында кечерәеп киткәндәй тоела. Җирдән карап торучылар аларны ярсу алкышларга күмә. Алар өчен җан атудан хәтта сулышлары киселеп китә, үзләре дә сизмәстән «Аһ!» дип куялар. Атынучылар күңелендә туган хис-тойгылар тамаша кылучыларга да күчә, аларны да бар дөньясын онытып дулкынланырга мәҗбүр итә. Тик барыбер… алар да бер җиргә төшәчәкләр һәм шулкадәр ашкынып, шулкадәр талпынып атынсалар да, беркая китә алмаганлыкларын аңлаячаклар. Авыр булыр инде аларга да.

Без бит үзебез кылган эшләрнең күбесен яратып башкарабыз. Теләр-теләмәс кенә башланганнарына да ияләшеп китәбез, мәҗбүри гамәлләргә дә җан җылысын кушарга тырышабыз. Җан җылысы кушылган эш кенә үзеңне җылыта ала. Шул яратып башкарылган эшкә кайчагында бөтен гомеребезне багышлыйбыз. Шуның белән дәртләнәбез, кинәнәбез, яңа үрләр яуларга, алдынгылардан булырга омтылабыз. Күп чакларда безнең гомер белән башка бернәрсә дә түгел, ә нәкъ менә шул югарырак күтәрелү, алдынгырак булу теләге идарә итә. Үз тизлегебездән үзебез тәм табабыз. Битебезгә килеп бәрелгән җилләр шул тизлекнең бер дәлиле булып тоела. Күз алдында биешеп якынайган йолдызлар галәмебезне киңәйткән кебек була, үзебезне дә йолдыз итеп тою мөмкинлеге бирә. Без үзебезнең чигенүебезне дә, артка киткән, түбән төшкән чакларыбызны да сизмибез. Сизсәк тә, моны нәкъ шулай булырга тиешле табигый хәл дип кабул итәбез. Алар бары тик көч туплау, яңа омтылыш өчен әзерлек мизгеле генә бит инде. Без үзебез барырга тиешле юлны һәм яуларга кирәк биеклекне генә күрәбез… Әнә ич, кылган гамәлләребезне күзәтеп торучыларның да дәртле алкышлары ишетелә. Димәк, барысы да яхшы, димәк, без – дөрес юлда.

Һәм бер мәлне җиргә төшәбез дә… беркая да китә, бер биеклеккә дә күтәрелә алмаганыбызны аңлыйбыз. Без бары тик атынгычта гомер уздырганбыз…

Бу тормыш атынгыч шикелле…

Премьера

НӘРСӘ ӨЧЕН КҮТӘРӘБЕЗ?

КАМАЛ ТЕАТРЫНДА – ПЬЕСА-БӘХӘС

Чәршәмбеме, җомгамы? Яңа гына Камал театрында премьерасы узган «Дуслар җыелган җирдә» спектаклен караган кешеләр бу сорауны үзләренә бирми калмагандыр. Һәрхәлдә, моның шулай булуына ышанасы килә. Атаклы драматург Туфан Миңнуллинның 50 ел элек язылган пьесасы кабат уйланырга мәҗбүр итте.

kamalteatr.ru

«Дуслар җыелган җирдә» – Камал театры сәхнәсендә өч мәртәбә куелган әсәр. Анда күтәрелгән тема-проблемалар, идея-фикерләрнең искермәвен шуннан гына да күреп буладыр. Трилогиянең («Миләүшәнең туган көне», «Дуслар җыелган җирдә», «Хушыгыз!») бәхәс аеруча куерган өлеше исә, тышкы каршылык аша эчке каршылык китереп чыгарып, геройлар белән бергә берничә мөһим сорауга җавап эзләргә этәрә. Бу җәһәттән аларның тамашачыга якынрак утырып, аның белән аралашуы пьесаның тәэсирен тагын да арттыра. Монысы – спектакльнең режиссеры Фәрит Бикчәнтәев пьесаны сәхнәләштергәндә керткән яңалык.

– Өч пьесаны берләштерү идеясе туды. Моның өчен һәр артист үзенең героена зур булмаган монолог уйлап чыгарды. Бу безнең өчен бик мөһим эксперимент булды, – ди режиссер бу турыда.

Нәрсә ул дуслык? Бу сорау спектакль дәвамында еш яңгыраса да, күбрәк фон буларак хезмәт итә. Әмма пьеса «Дуслар җыелган җирдә» дип атала – бу темага аерым тукталу, беренче чиратта, шуңа бәйле. Туфан Миңнуллин атамада ук бәхәс тудыра. Башта геройлар арасында эчкерсез мөнәсәбәтләр булуын күрсәк тә, ахыр чиктә без: «Нурислам (Искәндәр Хәйруллин), Миләүшә (Люция Хәмитова), Рәфис (Радик Бариев), Саҗидә (Алсу Каюмова), Фәһим (Фәнис Җиһанша), Эльмира (Венера Шакирова), Гайнулла (Зөлфәт Нуртдинов) һәм Галия (Эльза Моратхуҗина) чын дуслар булдымы икән соң?» – дип икеләнәбез. Бер уйласаң, дистә еллар буе бер-берсен мактап, анекдотлар сөйләшеп, кыяр тозлау серләрен бүлешеп, дуслык һәм сәнгать өчен «күтәреп» бәйрәм иткән кешеләрнең арасын әкият бозарга тиеш түгел кебек. Хәер, аларның арасын әкият түгел, хакыйкатьне кабул итә алмау боза.

Шулай итеп, Нурисламның яңа картинасын «юарга» җыелган «дуслар» ачуланышып таралыша. Режиссер аларның барысына диярлек соры плащ кидертә. Аны Нурислам гына кими. Бәлки, кайчандыр кигәндер, әмма хәзер ул нидер аңлаган, аның «соры масса»га иярәсе килми. Ул үзен эзли, иптәшләренә әкият сөйләп, аларны да шуңа этәрергә тели.

Без кем? Бу сорауны турыдан-туры бирмәсә дә, «Пәриләргә ярау максатыннан, «чәршәмбе» дип кычкырган егет өчен «күтәрәбезме», «бүген җомга бит» дип кычкырганы өченме?» – ди Нурислам. Аның нәрсә әйтергә теләгәнен иң беренче булып Нурисламның картинасын мактамый калган Эльмира аңлый. «Нульгә-нульне кушсаң, нуль була – гап-гади арифметика», – дип, ире Фәһимгә күпме гомерләренең бушка, ялган, мәгънәсез максатларга табынып узганын аңлатырга тырыша. Фәһим белән Эльмираларда гына түгел, калганнарда да йокысыз һәм иге-чиге булмаган төн башлана.

Тышкы бәхәс әкренләп эчке конфликтка әверелә. Геройларның бәргәләнүен режиссер төрлечә күрсәтә. Әйтик, «ни җыры, ни моңы» булмаган, әмма җырларга яраткан химик Гайнулла сузылып ук ята. Беркатлы тоелган герой: «Җырым да бар, моңым да бар – тавышым үземнеке түгел», – дип, җәмгыятьтәге тынчулыкка ишарә ясый. Хәер, ахыр чиктә дә ул, хыялына һәм үзенә тугры калып, авылга кайтып төпләнә.

Мин кем? Бу сорау геройларны янә Нурислам фатирына җыя. Димәк, Нурислам сөйләгән әкият үз эшен эшләде. Хәзер инде «дуслар» ачыктан-ачык сөйләшә. Ваемсызлык, битарафлык, яраклашырга тырышуга корылган тормыш рәвеше, декорацияләр ярдәмендә дә күрсәтелгән чиклелек эчендә «тыпырчыну» нәрсәгә илтәчәк? Без үзебезне дөрес бәялибезме? Үзебезгә хыянәт итүдән туктый алырбызмы?

Режиссер вакыт чикләрен билгеләргә ирек бирми. Ахырдан чыгып, 90 елларда популяр булган «Музыка нас связала» җырын башкаручы кызның кулындагы заманча смартфон бу чикләрне бөтенләй юып ташлый. Туфан абый бу сорауларны күптән күтәрсә дә, бүген тагын бер кат искә төшерергә кирәк дигән сыман…

Ә пәриләр кем? Ә пәриләр – һәркемнең үзенеке…

Фикер:

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ, әдәбият галиме, тәнкыйтьче:

– 50 ел элек язылган әсәр бүгенге көн сорауларына да җавап бирә. Туфан абый аны торгынлык чорында язган. Әсәрдә шушы торгынлык халәтен үтеп чыгу, кеше шәхесе, кеше иреге, аның үз-үзен табуы, башкалар сүзенә һәм теләгенә, идеология йогынтысына иярмичә, үзе булып калуы кебек мәсьәләләр күтәрелә. Бу мәсьәләләрнең спектакльдәге куелышын да кабул иттем. Режиссер буларак, Фәрит Бикчәнтәев чын мәгънәсендә артистлар ансамбле оештырган. Артистларның әсәрне, үз геройларын тирән аңлавы күренә. Алар пьесадагы «дуслар»ның гаҗәеп төрле булуын, әмма бер үк сорауларга җавап эзләвен, бер үк максатка хезмәт итүен оста күрсәтә. Әсәрдән аермалы буларак, спектакльдә геройларның үз-үзләренә бәя бирүе алгы планга чыккан. Ә Туфан абыйда һәр геройның шәхесе диалогларда ачыла. Гомумән алганда, режиссер пьесага тугры калган.

Авыл җаны

Кем сине яклар?

Авыл укытучысы портретына тагын берничә штрих сызып үтим әле. Болары – татар теле укытучылары (хәзер аларны «туган тел укытучылары» диләр, миңа никтер элеккечә якын). Иң яклаучысыз, «кирәксез фән укытучысы» буларак, иң кыен хәлдә калган укытучылар алар. Җитәкчесе милли җанлы булган мәктәптә генә кеше итеп сизә ала татар теле укытучысы үзен. Күңелне иң әрнеткәне шул.

Үз исемен әйтеп, фикерләрен җиткерергә теләгән татар теле укытучыларын таба алмадым. Һәм моңа һич кенә дә аптырамыйм. Ялгыш кына берәр тәнкыйть сүзе ычкындырып карасыннар, шунда ук район мәгариф бүлегеннән башка сугачаклар. Югарырак инстанцияләргә юлланган сораулар да кире әйләнеп кайта. Берничә укытучы шуңа мисаллар китерде. Бер укытучының «Ватсап» төркемендә язган «ялгыш» сүзен эләктереп алып, шул укытучыга карата экзекуция куллануларын да әйттеләр. Татар теле укытучысы авызыннан чыккан «ялгыш» сораулар шулкадәр «куркыныч» икән ул: «Ни өчен программалар үзгәреп тора? Ни өчен дәвамчанлык юк? Нигә «менә сиңа дәреслек, менә сиңа программа» дип әйтә алмыйлар безгә һаман? Башка фән укытучылары шулай эшли бит! Һ.б.»

Программа үзгәртеп, эшли генә башлыйсың, тагын нидер үзгәрә, диләр. Ә яңа программа буенча кайбер әсәрләр инде укылган, кайберләре укылмый калачак. Ни өчен төрле дәреслек авторлары, үзара килешеп, бер дәреслек чыгара алмый икән ул? Нигә һаман бер-берсен тәнкыйтьлиләр алар, дип гаҗәпләнә бер укытучы. «Нигъмәтуллина дәреслеге белән эшли башлыйсың, «Нигә Хәйдәрова буенча укытмыйсың?» – диләр; Хәйдәрова белән укыта башлыйсың, «Нигә Нигъмәтуллина түгел?» – диләр», – ди ул. Район үзәгендә эшләүче укытучы бу. Моннан ун ел элек тә шул ук хәл иде, гаҗәп! Мәгълүм мәсәлдәгечә икән хәлләр: «А воз и ныне там». Әле хәзер электрон дәреслекләр белән дә укыталар кайбер сыйныфларда. Ә баланың өендә интернет булмаса? Ә ата-анасы, телефоннан укып, күз бетереп утырма, дисә? Үзләре кәгазьгә чыгарып та тарата икән кайбер әсәрләрне укытучылар. Программага кертелгән, ләкин дәреслектә булмаган, интернеттан да, китапханәдән дә ул әсәрне тапмаган очраклар да була, диделәр.

Район үзәгендәге укытучыларның татар әтиәниләрнең үз балаларын, «укырга җиңелрәк» дип, рус төркемнәренә кертеп утыртуларына да күңелләре әрни. Татар теле дәресләрендә укучыларны үчти-үчти итеп кенә укытырга мәҗбүр булуларына эчләре поша. Укымаса укымасын, төркемдә утырсын гына. «Нинди сүз әйтү инде ул, Аллам сакласын!»

Татар авылларында хәлләр бераз башкачарак, әлбәттә. Анда укытучыга ихтирам саклана әле. Бигрәк тә укытучы үзе иҗади, фидакарь, хезмәтен яратып башкарса. Ләкин инде башлангыч сыйныфлардан урта сыйныфларга телне ярым-йорты белгән татар балалары килүенә алар да гаҗиз. «Рәхмәт, интернет».

«Рәхмәт, БДИ»: имтиханнарны русча биргәнгә, күп җирдә татар мәктәпләрендә дә кәгазьдә татарча, гамәлдә русча укыталар хәзер. «Рәхмәт, 2017 ел!» Бер сәгать әдәбият укытып кына укучыларның халкыбыз әдәби җәүһәрләрен аңлап, белеп, тоеп үсәчәгенә дә шик зур. Ярый ла мәдәният йорты, китапханә хезмәткәрләре үз миссияләрен аңлап эшләсәләр: ул очракта балалар барыбер дә татар мохитенә күбрәк тартыла, аларны гаджетлардагы урыс дөньясы йотмый.

Хәзер яңа электрон журнал платформасына күчә мәктәпләр. Башка фәннәр буенча темалар инде базада бар, ә без нишләргә тиеш икән, дип аптырый татар теле укытучылары. Анда теманы, өй эшләрен шул ук көнне тутырырга кирәк, үзгәртергә мөмкин түгел; ә безнең ни дәреслекләр, ни программалар буенча тотрыклылык юк, диләр. Бар икән монда хәлләр! Декрет ялында булган бер укытучы: «Яңа уку елында эшкә чыгарга җыенам, хәзердән үк котым очып тора; белмим, нишләп бетәрмен», – ди. Үз авылларында мәктәптә эш булмаганга, район үзәгенә йөреп эшли. Мәктәптән китәргә исәбе бар да… Балаларны үстерәсе бит, эш кирәк.

Авырткан башка – тимер тарак, диләрме әле. Инде бөтенләй диярлек чикләнеп, кысрыкланып беткән тел укытучыларының хезмәте җиңеләюгә таба бармый икән. Сөйләшүләрдән мин шуны аңладым. Ничә еллар буе сөйләнә килсә дә, дәреслек-программа проблемалары һаман да хәл ителмәгән әле. Боларны белә торып: «Балаларга туган тел укытачакмын!» – дип ашкынып торучылар булыр микән?

Лилия ФӘТТАХОВА

КҮГӘРЧЕН МӘХӘББӘТЕ

Әлмәт

Кайбер кешеләрнең йорт хайваннарына, терлекләргә исләре китсә, Әлмәт районының Кама-Исмәгыйль авылында яшәүче Гөлгенә һәм Әсгать Хәмидуллиннар кошларны бик ярата икән. Бүген гаиләнең 50ләп күгәрчене бар. Ә кайчандыр аларның саны 200гә җиткән булган.

Аеруча Әсгать абый мөкиббән күгәрченнәргә. Беренче карашка әллә ни матур да булмаган, бик тә гади кошларга ни өчене мөкиббән киткән соң гаилә башлыгы?

– Беренче күгәрченнәрне 7 нче сыйныфта укыганда алган идем. Армиягә киткәнче шактый үрчетеп, 22гә җиткердем. Тик туган якларга әйләнеп кайтканда, кошларым кайсы кая таралышып беткән иде инде. Бер елдан соң аларны тагын үрчетә башладым. Һәм менә 1970 нче еллардан бирле кошларсыз яшәгәнем юк. Мин алардан башка тора да алмыйм шикелле инде, – ди ул.

Бергә тормыш итәргә дә үзе шикелле үк күгәрчен җене кагылган Гөлгенә апаны сайлаган ул.

– Әсгать абыегыз кечкенә чагыннан ук уенчык белән түгел, каз йомыркасы белән уйнаган. Йомыркаларның кайсыннан ана, кайсыннан ата бәбкә чыгасын әйтеп бирә торган булган, – дип сүзгә кушылды ул. – Йомырка дигәннән, өйләнешкәч, күгәрчен астына тавык йомыркасы куеп, чеби чыгарганыбыз да булды әле безнең. Хәзер инде мин дә абыегызга охшап беттем. Бер арбага утыргач, икенчеңнең җырын җырлый башлыйсың икән ул. Хәер, миңа күгәрченнәргә мәхәббәт бертуган абыемнан да күчкәндер, дип уйлыйм. Ул мәктәптә укыган вакытта ук шушы кошлар белән кызыксынды. Һәм соңгы көннәренә кадәр аларны асрады.

Күгәрчен генә түгел, башка төрле кошлар, балыклар үрчеткән чаклары да булган Хәмидуллиннарның.

– Минем попугайларым да бар. Дөрес, сөйләшә торганнары юк инде хәзер. Алары аеруча кызык иде. Кенәриләрем дә бар иде. Аларын үзем чыгардым. 200 литрлы аквариумда алтын балыклар да тоттык. Тавыклар белән бергә йөри торган бик матур койрыклы парлы тәвә кошларыбыз да бар иде. Аларны өйләнешкән елны күгәрченнәр белән бергә Мәскәүдән алып кайткан идек, – ди хуҗабикә.

Хәзер алар «Күбәләк» токымлы һәм гади күгәрченнәр үрчетә. Әйтүләренчә, гади бер күгәрчен 500 сум тора. Соңгы тапкыр 3 пар кошны 6 мең сумга сатып алганнар. Бер пары 8 мең сум торган токымнар да бар, диләр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Без кошларның барысын да бары тик күңел өчен, матурлык өчен генә асрыйбыз. Бернинди файда да алганыбыз юк. Күгәрченнәр тәрбияләр өчен нәзберек түгел. Тавык нәрсә ашый, алар да шуның белән үк туклана. Ике төрле кошка көн саен бер чиләк бодай җитә, – ди Әсгать абый.

Анның әйтүенчә, күгәрченнәр бик тугрылыклы.

– Алар өчәр сәгать оча да кабаттан ояларына кайтып төшә. Холыклары төрлечә, ләкин күпчелеге тыныч. Читкә китми. Бервакыт Бөгелмәдә яшәүче бер гаилә, туйларында очыртырга дип, пар күгәрчен алып киткән иде. Шуларның берсе кире очып кайтты. Юкка гына пар күгәрчендәй тормыш теләмибез бит. Бу чыннан да шулай. Алар бик тугры. Токымнарын алыштыру өчен, берсе белән икенчесен парлыйм, тик барыбер аерылып, үз ярына әйләнеп кайта. Мин дә, үзләре төсле, күгәрченнәргә тугрылыклы. Бик яратам кошларны, – ди ул.

Әсгать абый күпчелек кошларына исемнәр биргән. Алай гына да түгел, барысын да таный, хәтта кайсының әнисе, әтисе икәнен дә әйтеп бирә ала икән.

– Анның бит аска, җиргә карап йөргәне юк. Карашы һәрвакыт өстә, күктә булыр, – дип сүзгә кушылды Гөлгенә апа. – Күгәрчене кайтмаса, йокламый да ул. Аягы авыртып, ике ел урын өстендә ятканда да, улыбыз ярдәме белән чыгып, шуларга ашарга биреп керә торган иде.

100 мең сумлык кош

Бишмунча авылында күгәрчен үрчетү белән шөгыльләнүче Шәүкәт Алеев яши. Бүген 50ләп кошы булса да, заманында 800гә кадәр җиткән.

– Күгәрчен белән кызыксына башлагансың икән, ул гомерлек мәхәббәткә әйләнә, – ди Шәүкәт абый. – Мин үз-үземне белә башлаганнан бирле шушы кошлар белән. 16 яшьтән шахтада эшләдем, хезмәт хакым яхшы иде. Күп йөрдем, дөнья гиздем. Заманында күгәрчен эзләп, бөтен Россияне йөреп чыктым. Украинаны җәяүләп диярлек аркылыга-буйга иңләдем. Сирәк токымлы күгәрчен өчен бервакытта да акча кызганмадым. Хәтта 100 мең сумга алган вакытлар да булды. Бу якларга күченеп кайтканда да аларны үземнән калдырмадым, 50сен генә булса да үзем белән алдым.

Заманында, әйткәнебезчә, Шәүкәт абый 800 кош асраган, хәзер төгәл санын белмәсә дә, якынча иллеләп тирәсе бар, ди. Күпчелеге «Николаевский» токымлы.

– Хәзер инде аларны тәрбияләр өчен саулык та җитәрлек түгел. Җәен йорт тирәли очып йөриләр дә кире кайталар. Туйлар, Җиңү бәйрәмнәре, Россия, Республика көннәре уңаеннан уза торган чараларга да сорап киләләр. Кызганмыйча бирәм, чөнки барыбер кире әйләнеп кайта алар. Хәзер колхоз, совхозлар бетте, амбарлар бушады, карчыгалар, ашарга эзләп, хуҗалыкларга киләләр. Ә карчыга өчен күгәрчен – иң җиңел табыш. Элек балалар белән бергә карасак, хәзер ара-тирә оныклар ярдәм итә, – ди күгәрчен үрчетүче.

Зөһрә САДЫЙКОВА

КҮГӘРЧЕННӘР ТУРЫНДА КЫЗЫКЛЫ ФАКТЛАР

✓ Йомырка салып, 18 көн утыра.
✓ Уртача 15 ел яши. Иң озын гомерлеләре – 30 ел.
✓ Әлеге кошларны кешеләр беренче тапкыр моннан биш мең ел элек кулга ияләштергәннәр.
✓ Ул элек-электән тынычлык кошы булып санала. Аңа 30лап шәһәрдә һәйкәл куелган.
✓ Аларның күзләре искиткеч яхшы күрә. Күгәрченнең күзен кояш та, яшен дә, эретеп ябыштыру аппараты да чагылдыра алмый.
✓ Дөньяда бу кошларның 700ләп төре бар.
✓ Күгәрченнәр 2 чакрым биеклеккә кадәр күтәрелә ала.

Ватан хакына

ВОЛОНТЕР АЛИНӘ: «ИРЕМ БЕЛӘН ГОРУРЛАНАМ!»

Арча

Арчаның Көтек авылында гомер итүче Азат Латыйповка 2022 елның 26 сентябрендә повестка килә. 8 айлык кызын сөеп тә туймаган Азат ныклы карар кыла: чакыргач, барам. Башка бу хакта сүз кузгатмыйлар.

Хатыны Алинә башта бер ай «Казан Экспо» юлын таптый, инде хәзер ай саен егетләргә гуманитар ярдәм җыеп җибәрә. Аны Арчада гына түгел, башка районнарда, хәтта күрше төбәкләрдә дә беләләр икән.

– Аерылышуны иң авыр кичергәне 11 яшьлек улыбыз Әмир булды. Әтисе – аның өчен, ул әтисе өчен өзелеп тора иде. Ә мин исә, никадәр читен булса да, балаларыма күз яшен күрсәтмәдем. Баштарак бик еладым. Волонтерлык эшенә керешкәч тынычландым, – ди Алинә.

Махсус хәрби операция башлануга, алар, берничә кеше, ирләрен, улларын көтүчеләрне җыеп, «Ватсап»та төркем ясыйлар. Әкренләп мондый төркем дүрткә җитә. Аннары район башлыгына барып: «Без эшләргә әзер, егетләргә ничек ярдәм итик?» – дип сорыйлар. Бөтен Арча халкы күтәрелә. Кем ничек булдыра ала, эшкә тотыналар. Алинә ике арада хәбәрче дә булып тора. Егетләр ни сорый, шуны юнәтәләр. Күчтәнәч, җылы оекбашларны исәпләп тә тормыйлар. Һәркем йөрәге кушканча, ярдәм кулы суза.

– Иремнең әти-әнисе белән яшәгәч, миңа җиңел. Бар нәрсәне бергә күтәрдек. Үз әти-әнием дә гел ярдәм кулы сузды. Балаларыма ныклы терәк булдылар. Ике як та оныкларны карап тора. Мин исә бар көчемне егетләргә ярдәм оештыруга бирдем, – ди ул. – Егетләрнең берсе дә чит түгел. Ирем дә аларның иң якын туганнарына әйләнүен әйтә. Бер-берләренә башын куеп йоклаган егетләр бит алар. Ирем ялга кайткач та, егетләр ничек икән анда, дип борчылды. Әле яраланып та кайткан иде. Мондагы көннәрен санап уздырды. Күңеле белән анда иде. Мин үзем дә гуманитар ярдәм алып бармакчы идем. Тик ирем, монда килеп йөрмә, дип кисәтеп куйды. Балалар өчен борчыладыр инде. Икебез дә чыгып китеп булмый бит.

Азат турында озак сөйли ала Алинә. Тормышта төрлечә сынала алар. Әмма бирешмиләр.

– Ул – үз сүзендә тора торган кеше, нинди генә хәл булмасын, аңа ышанырга, таянырга була. Мине үз ышыгында яшәтте. Әле дә еракта булса да, саклап, яклап тора. Минем белән горурлана да. Сине мондагы егетләр дә белә, ди. Мин дә бик горурланам. Чын ирләрнең йөзен менә шушы махсус хәрби операция күрсәтте инде, – ди ул.

Алинә гуманитар ярдәм белән дә булыша, егетләргә тиешле акча, гаиләләренә бирелә торган пособиеләр алганда килеп чыккан проблемаларны да хәл итәргә булыша. Тәҗрибәсе барлыгын белеп, аны «Ватанны саклаучылар» фондының Арчадагы социаль координаторы итеп тә билгеләп куйганнар.

– Махсус хәрби операция тормышны икегә бүлде. Элеккеге тормыш мәшәкатьләре, бер-береңә үпкәләп ятулар чүп икән алар. Парлап яшәгән чакларны бик сагынам. Исән-имин кайтсын иде дип телим, – ди Алинә. – Арча халкына рәхмәт әйтәсем килә. Без ярдәмне якташ егетләргә дип кенә җыймыйбыз. Миңа хәзер әллә кайлардан шалтыраталар. Башкортстан егетләре дә ярдәм сорый. Берәүне дә аермыйбыз. Ай саен пенсиясеннән 500, 1000 сум акча бирүчеләр дә, күп суммалар күчереп, исемен әйтмәүчеләр дә бар. Бездә бердәмлек көчле. Гел шулай авыр чакта ярдәмләшеп, шатлыкларны бүлешеп яшәргә язсын.

Сүз уңаеннан, шушы көннәрдә Арчадан тагын бер машина ярдәм киткән. Исемле посылкалар җыелган, берсе-берсе 280 мең сум торган ике квадрокоптер җибәргәннәр.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

✓ РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
✓ ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
✓ ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНҮ, ДӘВАЛАНУ ҺӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
✓ ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ
✓ 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
✓ ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ ҺӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
✓ КРЕДИТ ҺӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
✓ БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
✓ БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
✓ КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР ҺӘМ ГАРАНТИЯЛӘР

УКУЧЫ СҮЗЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ярсып-ярсып дулый әнә буран.
Һәр ярсуы
үзәгеңә кадәр үтәрлек.
Юк, уйлама, мин түгел ул,
сиңа күптән
күңелемдә һичбер үпкәм юк.

Юлларыңны кар көртләре күмсә
гаепләмә,
гаебең юк юлың күмәрлек.
Юкса, безнең сөю яра иде...
Яра тулы
яратудан шашып үләрлек.

Берни дәшмә: түгелергә торам!
Җанны кисә
үтә алмаган сөю чикләре.
Җанымны дөрләткән соңгы
мәхәббәтне,
ашыгуың белән чикләдең.

...Яңа сөю даулап китү түгел,
бу – нибары
синле дөньяны тик ятсыну.
Күчәреннән күчкән чакта галәм
кадәр галәм,
буран күмгән юлны тарсыну.

Гөлинә ШӘЙХИ

ГОМЕР ТӘЛГӘШЛӘРЕ

Язучы, галим Тәлгать Галиуллинның 85 яшьлек юбилее уңаеннан узган кичәдә үзем өчен өр-яңа сәхифәләр ачтым. Бәйрәмнең «беренче бит»ен ачып җибәргән Мирсәет Сөнгатуллинның «Кычытканлы авылы» җыры, көе һаман да күңел түрендә тора, тагын бер кат юбилярның туган авылы турында уйланырга мәҗбүр итте.

Урман уртасындагы бер аланлыкта, Мораса елгасы култыгында, Казан ханлыгы буйсындырылгач, көчләп чукындырудан качып, Болгар төбәгеннән, Әлкинең Узи авылыннан күчеп утырган куш йөрәкле, булдыклы кешеләр нигез салган бу авылга. Кичәнең башында ук искә алынып, исеме Галиуллиннар фамилиясенә «канат куйган» Галиулла бабайның алты кызы, ике улы дөньяга аваз салган монда. Ватан сугышына бер аягын «бүләк иткән» Нәбиулла да атасыннан калышмый: кулак кызы Исламия апа белән (әтисе Шәфигулла – репрессия корбаны) дүрт малай, дүрт кыз үстерәләр (барысы да югары белемле һәм залда утыралар иде). Тәлгать белән Әфхәт – фән докторлары, берсе – филолог, икенчесе – медицина белгечлеге буенча академиклар. Аларның эзләренә басып килгән энеләре Әсхәт белән Әхәт авыл хуҗалыгында хезмәт куялар, беренчесе – фәннәр кандидаты, төпчекләре – «Нурлат сөте» берләшмәсенең генераль директоры, күптән түгел министрның үз кулыннан рәхмәт хаты алган.

tatar-inform.ru

Барча туганнарын, дусларын бер залга җыйган Тәлгатьнең тормыш юлы гаҗәеп үзенчәлекле һәм гадәти кысаларга сыймый. Урта мәктәпне тәмамлаган көнне, чыгарылыш кичәсендә аягының баш бармагы тапочкасын тишеп чыгып, егетне «мыскыл итә» һәм ошатып йөргән кызын да озата алмаган мәгъшук әтисенең киңәше һәм кием-салым юнәтү ихтыяҗы белән Краснотуринск шәһәренә, әнисенең туганнары янына эшкә китә. Бер ел алюминий эретүче заводта тормыш мәктәбе узып, «баеп» кайта. Казан университетының татар филологиясе бүлеген уңышлы тәмамлаган үсмер шунда ук тел кафедрасында, Тел, әдәбият, тарих институтында берничә ел эшли. Аннары юллар аны Алабуга педагогия институтына алып килә. Язучы Хәсән Сарьян белән Тәлгатьне күренекле кырым татары галим Кәрим Җаманаклыны юбилее белән котларга җибәрәләр. Шунда фатир, «якты киләчәк» белән кызыктырып, галимне эшкә чакыралар. Ул ялындырып тормый, тиз генә күченеп тә килә. Татар, рус әдәбиятларыннан дәресләр алып барган егетне тиз бәялиләр: әүвәл декан ярдәмчесе итеп сынап караганнан соң, уку-укыту эшләре буенча проректор итеп куялар. Биш ел да үтми, 33 яшьлек галимне, инде фәннәр кандидатын ректорлыкка тәгаенлиләр. Ул шул чорда СССР югары уку йортларының иң яшь ректоры була. Алабугада эшләү дәверендә 840 урынлы тулай торак төзетеп, өч факультет янына бишне өстәп, өченче дәрәҗәдәге уку йортын беренчегә чыгарып, ике факультетны Чаллыга күчереп, яңа уку йортына нигез сала.

Административ эшләр белән башы әйләнеп китми, фән, тәнкыйть турында да онытмый ул. Фәнни язмалары 1960 нчы еллар уртасында матбугатта күренә башлый. Докторлык диссертациясен яклау мәшәкатьләре белән шактый үрсәләнергә туры килә галимгә. Мәскәү, Ташкент кебек шәһәрләрдә җылы мөнәсәбәт табылмагач, мосафир Алма-Атага юл тота. «Килмешәк»нең яклау көне җитәр алдыннан гына, советларының вәкаләт срогы чыккан булуы ачыклана. «Мәскәүгә тиешле кәгазьләрне син алып бар, сиңа кирәк, ректорның мөмкинлекләре күбрәк», – дип тә өстәп, тиешле кәгазьләрне кулына тоттырып, башкалага юллыйлар. Мәсьәләне уңай хәл итеп кайткач та, «эшебезне нугай баласын яклату белән башлап җибәрсәк, безне дөрес аңламаслар» дигән сылтау табып, янәдән сузалар.

Һәр кыенлыкның ахыр чиктә файдалы ягы да була дигәндәй, хезмәтен уңышлы яклап кайткан «иптәш», яклау советы Казаныбызда да булырга тиеш дип, «буза» куптара. Аны ул чорда абруйлы проректор Миркасыйм Госманов хуплап чыга һәм ярдәм итеп тора. Шул советта Татарстанның күп кенә күренекле галимнәре фәнни хезмәтләренә хуплау табалар. Тәлгать Галиуллин шунда яклаган дүрт фән докторының, егермедән артык кандидатның фәнни җитәкчесе була. Тугандаш милләт вәкилләренә дә ярдәм күрсәтелә.

Мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин юбилярга «Халык язучысы» исемен бирү турындагы указ белән таныштырды. Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире Ленар Шәех исә Тәлгать Галиуллинның сайланма әсәрләрен туплаган ун томлыкны үзенә тапшырды. Бу исә игълан ителгән указның гамәли расланышы кебек кабул ителде. Татарстан Фәннәр академиясе президенты, академик Рифкать Миңнеханов юбилярның гыйльми эшчәнлегенә тукталып, аңа фәндәге казанышлары өчен тәгаенләнгән алтын медаль тапшырды. Шул бүләк янына сугыш герое, галим, академик Мәхмүт Гәрәевкә атап чыгарылган алтын медаль килеп өстәлде. Филология һәм мәдәни бәйләнешләр институты директоры Рәдиф Җамалетдинов юбилярны университет җитәкчелеге исеменнән котлап, Тәлгать Галиуллинның шигърияте безне аркылыга-буйга иңләү белән генә канәгатьләнмичә, проза белән публицистикада да уңышларга ирешүен ассызыклады. Туганнары, якын дуслары исеменнән сүз алган медицина фәннәре докторы Әфхәт Галиуллин абыйсының үзенә һәм якыннарына фәнгә юл күрсәткәне өчен рәхмәтен белдерде.

Зур бүләкне галим Кремльдә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов кулыннан алды.

– Мәгълүм булганча, адәм баласының баш мие сәламәт булса, аның үзгә әгъзалары да камил эшлиләр, вак-төяк чирне, хәтта бәла-казаны да җиңел уздыралар. Икенче шарт – бердәмлек. Бергә булсак, без барча авырлыкларны да, язмыш сынауларын, иманым камил, җиңеп чыгачакбыз, – дип тәмамлады нотыгын «Халык язучысы» дип язылган күкрәк турысындагы билгесен сыйпый-сыйпый Тәлгать Галиуллин.

Юбилярның бүләк алуга буш кул белән килмәячәген дә сиземләгән идек. Ул Рәисебезгә соңгы елларда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Татар әреме», «Ана корт», «Мы – внуки страны Тартария» китапларын бүләк итте.

Николай МЫШЕВ

УРМАН ЮЛЫ

Безнең әни бер дә тик тора белмәде. Урманны ярата иде ул. Кышын чәйгә бик тәмле булганга, анда үскән җиләк-җимеш җыелмый калмый иде. Җәй башлануга каен җиләге өлгерә, аннары җир җиләге, соңрак кура җиләге. Әнинең бу җимешләрне җыя торган үзенә билгеле урыннары, аланнары бар. Кайсын каршыдагы Федот тавыннан җыеп төшәбез. Кайсын Бүләк чокырыннан барып җыябыз. Кура җиләген – Лоҗы урманыннан. Шомырт һәм карлыган Тәкмәк әрәмәлегендә иде. Үз чиратында мәтрүшкәсе, бөтнеге очрап тора. Аны да алып кайтып киптерәбез.

Әни фермадан сыер савып кайткан уңайга, туп-туры олы як бүлмәгә үтә дә, безне: «Торыгыз, торыгыз!» – дип, уята башлый. Идән тутырып җәелгән урын-җирдә чәчелеп яткан җирдән, көчкә күзне ертып торасың. Таң таралган гына диярлек, әле вакыт җиде дә тулмаган була. Ул арада кабаланып җыенабыз да җилдереп урманга чыгып китәбез. Алай иртә уятмас иде, кире сыер саварга әйләнеп кайтасы бар. Аннан кала, иртә торсак, әтинең, эшкә киткәнче, безне урман авызына кадәр булса да колхоз машинасында илтеп куярга җае чыга. Ул вакытта әти «ГАЗ-53» машинасын йөртә иде.

Кулдагы төенчектә тамак ялгап алырга йомырка, ипи, кыяр булыр иде. Сусыйсын белеп, өч литрлы бидонга чиста су ала идек. Кайчак аны урман буйлап сөйрәп йөри-йөри арып бетәсең. Бушагач, җиңел сулап куясың. Әле аны муенга асып, җиләк белән тутырасы да бар бит. Кайсы көнне су тиз бетә. Тамак кибеп, әнине кайтырга тарткалый башласаң, ул мәсьәләне бик тиз хәл итә иде. Урман юлларында яңгырдан соң җыелган суны, башыннан яулыгын салып, сөзеп бирә. Аны берсүзсез эчеп куясың.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Урман да әнине бик яратты! Ничә барсак та, ризыгын мулдан бирә иде. Бер дә буш чиләк тотып кайтканны хәтерләмим. Ул вакытта авыл халкының хаҗәте урманга нык бәйле иде бит. Йортлык диләнке кисәргә дисеңме, кыш ягарлык утын әзерләргә дисеңме, печән чабарга дисеңме... Шунлыктан урман машина юллары белән челтәрләнеп беткән. Әтинең мөмкинлеге булганда, әни генә белгән җиләкле аланга да илтеп куя. Алар икесе ничек сөйләшеп, ничек табышып беткәннәрдер. 6–7 сәгать буе урманны аркылы-торкылы йөреп бетергәннән соң, әни безне урманнан төп-төгәл тиешле урынга алып чыга. Озак та көттермичә, әтинең тузаннар туздырып элдергән машинасы күренә.

Тәкмәк әрәмәсенә әнкәй белән шомыртка барганда, олы юлга чыгып, Зәй ягына барган берәр машинаны кул болгап туктатасың. Урыс Тәкмәге исемле авыл Карман белән Зәй арасында кала. Ул авыл кырында киң җәелгән әрәмәлек бар иде. Шунда карлыган, шомырт үсә. Шомырт кына җыю димә! Шомыртны җыйганда да орып-җимереп җыярга ярамый, тәлгәшләп кенә чүпләргә рөхсәт ителә. Куагын сындырмаска, зыян салмаска кирәк.

«Ул көнне дә гадәттәгечә чиләк тутырып шомырт җыйдык. Өйгә кайтып, тиз генә өс-башны алыштырып, артык шомыртны Чаллыга сатарга алып барасы да бар. Сатылган акчага матур кием алырга сөйләшенгән. Әнкәй, машинада утыртып кайткан шоферга, гәҗиттән кулёк ясап, мулдан шомырт салып бирде. Ходай биргән җимеш белән бүлешә дә белергә кирәк бит. Чаллыга да барып җиттек, шомырт та сатылды. Шатланып, хыялланып, кием сайлап, кешеләрне күзәтеп утырам. Карасам, безне Тәкмәктән утыртып кайткан абый әни биргән кулегын күтәреп минем тирәдән үтеп бара. Эшен тәмамлап, гаиләсенә кайтуыдыр инде. Бик кызык тоелган иде бу хәл. Ул елны шомырт саткан акчага куртка алдык, яратып, саклап кидем мин аны», – дип искә ала сеңлем Флүзә. Табигатьне яратырга, максатыңа ирешергә, бүлешә белергә, хезмәтнең бәясен, акчаның кадерен белергә өйрәткән әни. Үзең эшләп алган акчага кием алгач, димәк, кадерләп киясең.

Фирдәүсә БИКМӘТОВА

Төн эчендә әтиемнең чәче агарды

Яшел Үзән районы Бакырчы авылында яшәүче туганнарым Динә һәм Равил Насыйбуллиннарның быел февраль аенда алтын туйлары.

Равил абый 30 елдан артык районыбызда авыл хуҗалыгы өлкәсендә хезмәт итте, бригадир вазыйфаларын башкарды, алдынгы комбайнчылар рәтендә булды. Илкүләм газлаштыру чоры башлангач, районыбыздагы авылларны газлы итү эшенә керешеп, бик күпләргә зәңгәр ягулык бүләк итте. Һәр эшне зур җаваплылык белән, җиренә җиткереп башкарды, үзенә дә, башкаларга да таләпчән булды. Осталыгы һәм оештыру сәләте, алтын куллы булуы, тырышлыгы һәм ярдәмчеллеге, тормышны яратуы белән Равил Габделкәрим улы хезмәттәшләре һәм район халкы алдында олы хөрмәт казанды.

Динә апа хезмәт юлын укытучы буларак башлап, 30 елдан артык китапханәче булып эшләде. Кешеләрне ярату, хезмәт сөючәнлек, яңалыкка омтылу, куйган максатларга ирешү кебек асыл сыйфатлар хас аңа. Укыткан укучылары, китап укучылары, бергә эшләгән хезмәттәшләре күңелендә аңа карата хөрмәт хисләре гел саклана.

Илле ел гомер эчендә гаиләне бөтен, күркәм итеп саклап калу өчен, минемчә, бик күп көч кирәктер. Хатын-кызның сабырлыгы да, ир-атның ныклыгы да, балаларга бирелгән олы тәрбия дә, туган җанлылык, тырыш хезмәт, килгән авырлыкларны җиңеп чыгарлык бердәмлек тә, сынауларда сынмас-сыгылмас көчле рух, иманлылык та кирәктер.

Икенче уллары сөйләгән вакыйга һич исемнән чыкмый.

– Авыр хәлдә хастаханәдә ятканда, табибларның: «Төн эчендә аягы суынмаса, аякны саклап калып булачак», – дигән сүзләреннән соң, әтинең төне буе аякны тотып утыруы, шул вакыт эчендә чәчләренең агаруы күз алдымнан китми», – дигән иде ул.

Сынауларны ничек кичергәннәрне сөйләп кенә бетереп булмый. Равил абыйның өздереп уйнаган гармун көйләрендә, аңа кушылып җырлаучы Динә апаның иситкеч моңлы тавышында сизеп була аны...

Равил абый белән Динә апа өч бала тәрбияләп үстерделәр, оныкларына әби-бабай җылысы бирәләр. Һәр бала, онык өчен горурланып яшиләр. Ярдәмчел, туган җанлы, хезмәт сөючән, тырыш, иҗади һәм иманлы бу гаилә. Алтын туеңны кадерле балаларың, сөекле оныкларың, туганнарың белән бергәләп каршы алу – Аллаһ бүләгедер.

Гаилә елында илебездә бик күп гаиләләргә алтын туйларын каршылап, алга таба да имин илебездә тигезлектә яшәргә насыйп итсен иде.

Гөлназ ИСМӘГЫЙЛЕВА

Бар өмет– балаларда

Безнең авыл яши әле. Мәчетебездә азан тавышы яңгырый. Яше-карты дин сабагын өйрәнә. Ел буе укыганнан соң, аларны зурлап бүләклиләр дә әле. Апас районының Коштавылы мәдәният йортында менә шундый чара узды. Бездә бу көнне «Догачылар булсын балаларыбыз» дигән чара узды. Бу бәйге өченче тапкыр уздырыла инде.

Сабыйларның кул күтәреп дога укып торуы күңелгә рәхәтлек бирә. Сабыйлар күңеленә изгелек орлыклары салуда авылыбызның күренекле кешеләре зур роль уйный. Казандагы Апас якташлык җәмгыяте әгъзалары якташларыбыз Наил Галиуллин, Рәшит Байбиков, балалар дин сабаклары алсын өчен, бөтен мөмкинлекләрне тудыралар. Әхлак дәресләрен Гөлназ Латыйпова алып бара.

Бер тарыдан ботка пешми, диләр бит әле. Бездә дә шулай. Балаларга дин сабаклары укытылсын өчен башка авылдашлар да үзеннән өлеш кертә.

Кәфил Гыйmранов, Гөлсинә Галиуллина, Ленар Гыйсмәтуллин, Ягъфәр Әхмәтов, Фиргат Вәлиев сабыйларны тәмле ризыклар белән сыйлап, аларның чәй табынына күчтәнәч алып тора.

Шөкер, балалар догаларын бик теләп өйрәнә. Ахырдан инде, нәтиҗә ясап, ел саен аларны бүләклибез. Бәйрәмебезгә Апастан ук килгән имам мөхтәсиб Мидхәт хәзрәтнең укыган вәгазьләре дә һәр кешенең күңелендә хуш килде. «Апас» якташлык җәмгыятенең вице-президенты Наил Галиуллин белән Ленар Гыйсмәтуллин сабыйларны курчак театры белән сөендерде. Укучыларны авылыбызның имамы Ислам хәзрәт тә бүләксез калдырмады. Рәшит Байбиков исеменнән сабыйларга Яңа ел бүләге таратылды. Авылны яшәткәннәре, аның киләчәген кайгыртканнары өчен якташларга чиксез рәхмәт.

Тәскирә ХАФИЗОВА

Белдерү

Паспорт РФ 9204 № 692974, выданный ОВД Кукморского района Республики Татарстан 01.11.2004 г. и форма 1 П, в связи с утерей считать недействительными и аннулированными.

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Рафис КОРБАН

Болытлар

Ап-ак болытлар оча,
Вак-вак болытлар оча.
Ни кадәрле су оча
Яңгыр булып яумыйча.

Яңгыр ява болытлар
Су белән тулса гына,
Авырлыкка түзмичә,
Төбе ертылса гына.

Бабай

Бабайның өч аягы,
Өченчесе – таягы.
Атлый алмый таяксыз,
Тәмам кала аяксыз.

Күзлексез дә йөрми ул,
Чөнки берни күрми ул.

Ләкин менә урамда
Мин җитәкләгән чакта,
Кирәк түгел күзлек тә,
Кирәк түгел таяк та.

Ярдәм итәр идем...

Урамда бар тирә-якны
Барам биектән карап.
Зур гына сумка күтәреп,
Әнә бер апа бара.

Сумкасы бик авыр бугай,
Атлый ул көчкә генә.
Әле бер кулына ала,
Әле икенчесенә.

Ул апага рәхәтләнеп
Ярдәм итәр идем дә,
Мин үзем дә барамын шул
Әтиемнең иңендә.

Табышмаклар

БУ НӘРСӘ БУЛА?

Һаман бергә атлыйлар,
Бер-берсеннән калмыйлар.
Һаман юлда үзләре,
Җирдә кала эзләре.
(А...)

* * *

Түбәсендә кыш –
Ап-ак кар ята.
Итәгендә җәй –
Гөл чәчәк ата.
(Т...)

* * *

Үзе таш, үзе биек,
Болытка тора тиеп.
Болыт өчен ул бишек,
Исеме аның ничек?
(Т...)

* * *

Дүрт аяклы,
Бер куллы.
Кул дигәнең –
Борыны.
(Ф...)

* * *

Күккә менсә – оча,
Җирдә булса – ага.
Салкын кыш җиткәч,
Әверелә карга.
(С...)

* * *

Суда йөзә, көймә түгел.
Эт түгел, койрыклы.
Канаты бар, кош түгел,
Кеше түгел, мыеклы.
(Җ... б...)



СӘИД ГАЛИУЛЛИН:

«ҖЫРЛЫЙ-ҖЫРЛЫЙ ОПЕРАЦИЯЛӘР ЯСАЯЧАКМЫН»

Бүгенге кунагыбызны хәзер Татарстанда гына түгел, Россиядә дә яхшы беләләр. Күптән түгел Беренче каналда «Лучше всех» тапшыруында катнашып, «Иделләре» җырын башкарып танылган 11 яшьлек Сәид ГАЛИУЛЛИН турында сүзебез. Үзе тыйнак, үзе талантлы егет белән без дә аралаштык.

Сәид Галиуллинның шәхси архивыннан

:: Сәид ничә яшьтән сәнгать өлкәсендә кайный инде?

Сәиднең әнисе Эльвира:

– Сәиднең җырга сәләте кечкенәдән бар. 2 яшьтән өйдә җырлар көйләп йөри иде. 7 яшьтән сәхнәгә чыга башлады. Мин – әни дә, җыр буенча укытучысы да. Сәиднең күңеле татар халык җырларына, эстрада җырларына тартыла. Хәйдәр Бигичев, Илһам Шакиров иҗатын бик ярата. Аларның репертуарын башкара. Әле менә Сарманда узачак «Илһам чишмәсе» дигән бәйгегә әзерләнәбез.

:: «Лучше всех» тапшыруына ничек эләктегез?

– Кастинг буласын белгәч, барып, үзебезне сынап карарга булдык. Сәид башта бер татарча җыр гына әзерләгән иде, әллә бишне, әллә алтыны җырлады. Аннары безне Мәскәүгә чакырдылар. Буран вакыты иде, самолетлар очмый, рейсларны күчерәләр, поездлар да йөрми башлады. Бураннан курыкмыйча, машинага утырып, Мәскәүгә юл тоттык. Безне әйбәт каршы алдылар, Сәидне бик яраттылар. Балалар өчен үлеп тора торган кешеләр эшли анда.

:: Сәид, тагын нинди телләрдә җырлыйсың?

– Русча, итальянча да җырлыйм. Элекке, совет чоры җырларын яратып башкарам. «Батыр егетләр» дигән ансамбльгә йөрибез. Абыем Әмир белән «Батырлар» дуэты буларак чыгыш ясыйбыз.

:: Сәхнәгә чыкканда дулкынланмыйсыңмы?

– Әзрәк дулкынланам, ләкин мин аны тиз җиңәм. Тирән сулыш алам һәм җырлый башлагач, үзеннән-үзе бетә ул.

:: Татар җырчыларыннан кемнәрне тыңлыйсың?

– Илһам Шакиров, Хәйдәр Бигичев, Ришат Төхвәтуллин, Элвин Грей, Винера Ганиева, Зилә Сөнгатуллина репертуары ошый.

:: Син бит әле дзюдо белән дә шөгыльләнәсең. Җыр белән спортны бергә алып бару кыен түгелме?

– Дзюдо белән җиде яшьтән шөгыльләнәм. Беренче яшүсмер разрядым бар. Җыр белән дзюдоны бергә алып бару кыен түгел. Алар берсе-берсенә комачауламый, киресенчә, тулыландырып тора. Икесенә дә дөрес сулау, осталык һәм чыдамлык кирәк.

:: Тагынниләр белән кызыксынасың? Ялыңны ничек уздырырга яратасың?

– Велосипедта, самокатта йөрергә, футбол уйнарга яратам. Кыш көне чаңгы шуам.

КУНАГЫБЫЗ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ

- Казанның 183 нче гимназиясендә 5 нче сыйныфта белем ала.
- Ике яшьтән җырлый, дүртенче ел дзюдо белән шөгыльләнә.
- Халыкара һәм илкүләм конкурслар лауреаты, Татарстан Рәисе стипендиаты.
- Киләчәктә җырчы һәм табиб булырга хыяллана.

:: Ничек барысына да өлгерәсең? Укырга вакытың каламы?

Сәиднең әнисе Эльвира:

– Төннәрен дә утырабыз кайчак. Бәйгеләр булганда, кич белән кайтып, өй эшләренә тотына. Мәктәп эше генә түгел, Сәид өйдә дә булыша, 5 яшьлек энесен караша. Инде хәзер ул да җырлый, сәхнәгә беренче адымнарын ясый башлады.

:: Сәид, үскәч, кем буласың килә?

– Табиб һәм җырчы буласым килә. Җырлый-җырлый операцияләр ясар идем. Хыялым – шәп хирург һәм танылган җырчы булу.

Хикәя

ӨРӘК АУЛАУ

dreamstime.com

Мәктәп коридоры буйлап атлаганда, завхоз Хисмәт абый «Хенде хох!» дип кычкырган тавышка сискәнеп китте һәм ике кулын берьюлы өскә күтәргәнен сизми дә калды. Бераз исенә килгәч кенә, коридорның бөтенләй буш икәнен, ә тавышның янәшәдәге кабинеттан килгәнен абайлады. «Дивана! – дип үзен сүкте. – Соң, рус теле кабинетында балалар кинофильм карыйлар лабаса! Вәт карт җүләр!»

Әйе-е-е... Хисмәтләр мәктәптә укыганда, кинофильмы түгел, диафильм дигәннәре дә юк иде әле. Дүрт класслы авыл мәктәбенә каян килсен ди! Хәзер генә ул, мәктәптә җаның ни тели, барысы да бар! Һи-и-и, без бала чакта булсамы андый хикмәтләр! Белер идек нишләргә кирәген! Хәзергеләр шикелле урамда трай тибеп йөрмәс идек...

Шулай уйлана-уйлана Хисмәт абый алга атлавын дәвам итте һәм көтмәгәндә:

– Агиюки!!! Гюкосоки!!! – дип илереп кычкырган тавыш ишетеп, янә туктап калды. Тавыш спортзал ягыннан килә иде. «Сүгенәләр...» – дип мыгырданды өлкән яшьтәге завхоз, ишек ярыгыннан эчкә күз ташлап. Әмма ялгышкан булып чыкты. Унберенче класс малайлары каратэ-до алымнарын үзләштерәләр икән.

«Ә безнең хәтта футбол тубыбыз да юк иде, – дип, сагышлы гына уйлап куйды Хисмәт ага. – Физкультура дәресендә каткан сыер тизәген туп итеп тибеп йөри идек...»

Биредә нинди дәрес бара икән, дип, ул чираттагы ишеккә колагын якын китерде һәм... чак кына егылып китмәде! Эчтә уфылдаган, кычкырган тавышларга кушылып, кемдер: «Эченә када!!! Пычак белән, пычак белән!!!» – дип шәрран яра иде. Хисмәт абый бар көченә ишекне үзенә тартты, әмма ул ачылмады, эчтән бикле иде. Алда торган хәвефне сизенеп, завхозның йөрәге кысылып куйды. Ул бар көченә ишекне шакырга тотынды. Әмма аны ишетүче булмады, киресенчә, эчтә бер малайның: «Башын чабып өз!» – дип кычкырганы ишетелде.

Инде Хисмәт ага үзен белештерми ишеккә аягы белән тибәргә тотынды:

– Ачыгыз! Хәзер үк ачыгыз дим! Ишетәсезме?!

Аның тавышына күрше кабинетлардан укучылар, укытучылар чыга башлады. Ул арада эчтә: «Йөрәген чокып ал!» – дигән фәрман ишетелде. Ыңгырашкан, уфылдаган, чинаган тавышлар инде коридорга ук аермачык булып ишетелә иде. Өлкән класс малайларының берсе, хәлнең җитдилеген аңлап, йөгереп килеп, бар көченә ишеккә китереп типте. Ишек тупсасы-ние белән эчке якка шапылдап барып төште һәм алда шундый күренеш ачылды...

Орчык хәтле генә ике малай компьютер каршына утырганнар, компьютерның тавыш колонкаларын соң чиккәчә акыртып, «Өрәк аулау» дигән уен уйнап утыралар, малайларның берсе, арттагы халыкны күрмичә, һаман да: «Колагын аша, колагын аша!!!» – дип шәрран яра иде.

Алмаз ГЫЙМАДИЕВ

Тест

Казан сөйли!

13 февраль – Бөтендөнья радио көне. Бу бәйрәмне беренче тапкыр 2012 елда билгеләп узалар. Радио тарихы турында ниләр беләсез? Әйдәгез, тикшереп карыйк.

1. Радионы кем уйлап тапкан?
А. Генрих Герц.
Б. Павел Яблочков.
В. Александр Попов.

2. Россиядә радио көне кайчан билгеләп үтелә?
А. 20 октябрь.
Б. 7 май.
В. 18 апрель.

3. Бөек Ватан сугышы хәбәрләрен кайсы диктор җиткереп торган?
А. Юрий Левитан.
Б. Игорь Кириллов.
В. Юрий Никулин.

4. Татарстан радиосы кем тырышлыгы белән барлыкка килә?
А. Рәзин Нуруллин.
Б. Шамил Усманов.
В. Минтимер Шәймиев.

5. Татарның беренче дикторы кем?
А. Гадел Кутуй.
Б. Әмирхан Еники.
В. Фоат Галимуллин.

Безгә язалар

Утырыйк та бер уйланыйк әле

Утырыйк та бер уйланыйк әле,
Әниләрне аңлый беләбезме?
Безнең өчен күпме борчу күреп
Яшәүләрен соң без күрәбезме?

Һәрчак нидер тиеш кебек безгә:
Тиеш алар безне аңларга,
Тиеш безне тәмле ашатырга,
Бездән калса була аларга.

Киемнең дә кирәк яхшырагы –
Алар олы, без бит яшерәк.
Без өйрәнгән инде, өлешнең дә
Алар алганы бит кечерәк.

Утырыйк та бер уйланыйк әле,
Әниләрнең күңелен күрәбезме?
Сирәк кенә булса да ратып,
Бер җылы сүз әйтә беләбезме?
Утырыйк та бер уйланыйк әле!

Зилә ГАБДРАХМАНОВА,
Арча районы Наласа урта мәктәбенең
11 нче сыйныф укучысы

Сәхифәне Ләйсән САФИНА әзерләде

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 2061 данә
Гомуми тираж – 11272 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 216

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+